ЮЕШ КУРКЫНЫЧ

Сулыкларны яраксыз хәлгә килгән торбалар да пычрата

> 3

ЛИАНА ИСМӘГЫЙЛЕВА:

«Яхшы табиб булырга сүз бирәм!»

> 5

ХАТЛАРДА – ЙӨРӘК ЖЫЛЫСЫ

Укучыларыбыз кадерле истәлекләре белән уртаклаша

> 7

МИЛЛИ АККОРД

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче халыкларның милли уен кораллары турында махсус проекты

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 120–121 (29087–29088) | Сишәмбе | 22 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КАЕШ КИРӘК

Татарстан юлларында зыян күргән балалар саны арта! Юл иминлеге сагында торучылар шулай дип чаң суга. Андый чакта гаеп атта да, тәртәдә дә була, билгеле. Әмма сүз балалар турында барганда, төп җаваплылык ата-ана җилкәсенә төшә, ди белгечләр. Яңа уку елы башланыр алдыннан балаларны да, ата-аналарны да аеруча уяу булырга чакыра алар.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясе идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Айрат Сәмигуллин сүзләренә караганда, ел башыннан бирле республика юлларында 9 баланың гомере өзелгән. Белгечләр чаң суга: узган ел республикада ел дәвамында (!) шулкадәр фаҗигале очрак теркәлгән булган. Агымдагы ел башыннан бирле республикада балалар катнашында барлыгы 278 юл-транспорт һәлакәте килеп чыккан. Аларда 291 бала җәрәхәтләнгән.

Юл һәлакәтендә күбрәк пассажир балалар зыян күрә. Ел саен шул хәл. Быел республикада пассажир балалар катнашында 127 юл һәлакәте килеп чыккан. Бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 35 очракка күбрәк. Айрат Сәмигуллин, юлдагы мондый аянычлы очраклар еш кына гади генә кагыйдәләрне үтәмәү аркасында килеп чыга, дип кисәтә.

– Салондагы баланың гомере өчен тулысынча машина йөртүче җаваплы. Ни кызганыч, гади генә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәмәү аяныч тәмамланырга мөмкин. Машинада барганда бала кулда булса, бигрәк тә. Машина кисәк кенә туктаганда, бәрелгәндә, пассажирның авырлыгы берничә мәртәбә арта. Шуңа күрә андый чакта баланы бәрелү, имгәнүләрдән саклап калу мөмкин түгел, ул махсус кәнәфигә утырган булырга тиеш, – ди ул.

Юлдагы хәлләр дә бу сүзләрнең хаклыгын раслый. Хәтерләсәгез, 6 август көнне Арча – Олы Әтнә юлында коточкыч авария булды. «LADA» машинасы тракторга килеп бәрелү аркасында өч кешенең, шул исәптән биш яшьлек баланың гомере өзелде. Айрат Сәмигуллин сүзләренә караганда, әби-бабасы белән өенә кайтып барган бала махсус кәнәфигә утырмаган булган.

– Машинада бала булганда җаваплылык икеләтә арта. Йөртүче тизлекне арттырмаска, һава торышын исәпкә алып хәрәкәт итәргә, арыган килеш рульгә утырмаска тиеш, – ди Айрат Сәмигуллин.

Сан

Агымдагы ел башыннан бирле республика юлларында барлыгы **2 мең**нән артык юл һәлакәте килеп чыккан. Аларда **158** кешенең гомере өзелгән. **2,5 мең**нән артык кеше төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Балалар кәнәфие үлем-китем очракларын – 54 процентка, имгәнү ихтималын – 76 процентка, авыр тән җәрәхәтләре алу куркынычын 92 процентка киметә. Күпсанлы тикшеренүләр ярдәмендә күптән расланган факт бу.

Ел башыннан бирле балалар катнашында килеп чыккан юл фаҗигаләренең өчтән берен җәяүлеләр катнашындагысы тәшкил итә. Белгечләр бу очракта да балаларга юл аша чыгу кагыйдәләрен, аерым алганда, рөхсәт ителгән урыннардан гына чыгарга яраганлыгын кат-кат аңлатырга өнди. Мондый фаҗигаләрне кисәтү өчен, баланың киемендә яктылык кайтаргыч элемент та булырга тиеш, ди алар. Финляндиядә, әйтик, моны закон белән мәҗбүр итәләр. Андый тәртип гамәлгә кергәч, җәяүле балалар катнашындагы юл һәлакәтләре саны 75 процентка кимегән.

– Ата-ана баласына скутер, мопед, мотоцикл ише кәттә бүләк ясар алдыннан да җиде кат уйласын иде. Юкса, күпләр боларның ни дәрәҗәдә куркыныч бүләк икәнен фаҗига булгач кына аңыша, – ди Айрат Сәмигуллин. – Мисал өчен, май башында Әлмәттә мотоцикл белән идарә иткән бер баланың гомере өзелде. Аның өстенә «Опель» машинасы килеп менгән. 14 август көнне Лаешта да шундый ук фаҗига булды. Питбайк (мотоциклның бер төре. – **Ред.**) белән идарә иткән 14 яшьлек малай «ГАЗель» астына килеп кергән. Бәхеткә, ул исән калды, төрле тән җәрәхәтләре белән хастаханәгә озатылды. Ә бит мондый төр техника белән ябык паркларда саклагыч җайланмалар киеп кенә йөрергә ярый.

21 август – 10 сентябрь аралыгында Татарстанда «Игътибар: балалар!» акциясе уза. Акция барышында инспекторлар мәктәп юлларының, балаларны укырга йөртүче автобусларның торышын тикшерәчәк. 1 сентябрьдә исә ЮХИДИ инспекторлары мәктәп яннарында сакта торачак.

Юл сагында торучылар мәктәптә укулар башланыр алдыннан ата-аналарны аеруча уяу булырга чакыра.

– Ата-ана баласы белән көн дә сөйләшү, аңлату эшләре алып барсын иде. Бала юлның хаталарны кичермәвен белеп торырга тиеш. Юлда йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәргә кирәклеген үз мисалыгызда күрсәтегез. Балагыз белән аның мәктәпкә яки башка урыннарга йөри торган юлларыннан җәяү барып, андагы куркыныч урыннарны тикшерегез, – ди Айрат Сәмигуллин. – Машина йөртүчеләр дә игътибарлырак булсын иде. Юлда, бигрәк тә мәктәп, җәяүле кичүе яннарында тизлекне киметергә, куркынычсызлык каешын эләктерергә онытмасыннар, балаларны фәкать махсус кәнәфидә генә утыртып йөртсеннәр.

Ким булмасын

Студентларның стипендиясе МРОТ (хезмәткә түләүнең минималь күләме) күләменнән ким булмаска тиеш. Депутатлар Россия Дәүләт Думасына шул хакта закон проектын тәкъдим иткән.

Аңлатма язуында билгеләп үтелгәнчә, югары уку йортларында укучылар өчен айлык стипендия күләме – 1825, колледж студентлары өчен – 664, социаль яктан якланмаган студентлар өчен дәүләт стипендиясе күләме – 2739, ә махсус уку йортларында 996 сумны тәшкил итә. «Мондый стипендиягә яшәү мөмкин түгел, статистикага караганда, күпчелек студентлар уку белән эшне бергә алып бара. Бу укуга дигән вакытны ала, кайбер очракта вузны ташларга мәҗбүр итә. Бу инде белем алу сыйфатына йогынты ясый», – ди закон авторлары.

Шунысын да искәртик: Россия Президенты Владимир Путин МРОТ күләмен арттыру турында указ имзалаган иде. Хәзер ул аена 16242 сумны тәшкил итә.

Уч тутырып алалар

Татарстанда 80 яшьтән өлкәнрәк 140 меңнән артык кеше югары күләмдә пенсия ала. Бу хакта Россия Социаль фондының Татарстандагы бүлекчәсе хәбәр итә.

Билгеле булганча, бу елның 1 гыйнварыннан картлык буенча пенсиянең фиксацияләнгән күләме 7567,33 сумны тәшкил итә. 80 яшенә җиткән һәм иминият пенсиясе алучылар өчен акчалата түләү күләме ике тапкыр арта һәм 15 мең сумнан артык була.

Фондтан хәбәр итүләренчә, мондый түләүне алу өчен, бернинди гариза тапшыру кирәкми. Социаль фонд хезмәткәрләре моны үзләре башкара.

Картлык буенча социаль пенсиягә яки инвалидлык буенча пенсиягә мондый үзгәрешләр каралмаган. Туендыручысыз калган өчен билгеләнгән пенсия алучыларның да арттырылган пенсиягә хокукы юк.

Белем ишекләре ачыла

Капиталь төзекләндерүдән соң Россиянең 73 төбәгендә 1293 мәктәп ачылачак. Моннан тыш, яңа уку елы башланганда, 150 яңа мәктәп ачылачак һәм бу ел азагына тагын 400гә якын мәктәп төзеләчәк. Бу хакта «Бердәм Россия» партиясенең Генераль советы секретаре Андрей Турчак хәбәр итте.

Аның сүзләренчә, төзекләндерү эшләре 70–99 процентка төгәлләнгән. 3 мәктәпне ремонтлау буенча килешүләр яңадан төзелгән. Кайбер белем бирү оешмаларында исә алдан ниятләнмәгән эшләр килеп чыккан.

Андрей Турчак әлеге юнәлештә үрнәк булырлык төбәкләрне атаганда Татарстанны да телгә алды.

Сагындырыр җылысы

Татарстан Гидрометүзәге бу атнага һава торышы ничек булачагын әйтте.

Мәгълүм булганча, узган атна якшәмбесендә республикада һава температурасы үзгәрде – суытты. Синоптиклар атна дәвамында салкынча булачак дип кисәтә.

22 августта явым-төшем көтелми. Төнлә һәм иртән томан фаразлана. Төнлә температура +4…+9 градуска кадәр төшәчәк, көндезге һава торышы +19…+24 градустан югары булмаячак.

Чәршәмбе, 23 августта, иртән һәм көндез кайбер районнарда кыска вакытлы яңгырлар явар дип көтелә.

Пәнҗешәмбедә урыны белән кыска вакытлы яңгыр булыр дип фаразлана. 25–26 августта да кыска вакытлы яңгырлар яварга мөмкин. Һава торышы төнлә +5…+10, көндез +14…+19 градус тирәсе булачак.

Вазгыять һәм гамәл

Дуслар җыелган җирдә

Көнчыгышка күперне Татарстан аша салалар. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның кабул итүче як чакыруы буенча Венгриягә ике көнлек эш визиты уңаеннан белгечләр әнә шулай ди.

Будапештта милли бәйрәм – Дәүләт төзелү көне уңаеннан тантаналы рәсми чара узды. Бәйрәмнең дәрәҗәле кунаклары арасында Рөстәм Миңнеханов белән беррәттән, Азәрбайҗан, Сербия, Кыргызстан, Төркия, Төрекмәнстан, Үзбәкстан Президентлары һәм Катар Әмире дә бар иде.

Тантаналы чарага кадәр Татарстан Рәисе Венгрия Премьер-министры Виктор Орбан белән очрашты.

– Татарстан белән Венгрия арасындагы хезмәттәшлек Россия – Венгрия мөнәсәбәтләре кысасында алып барыла. Дөньядагы вазгыятькә дә карамастан, безнең арада тотрыклы һәм дустанә мөнәсәбәтләр саклана, – диде Рәис.

Узган ел нәтиҗәләре буенча, ике арада товар әйләнеше ике тапкыр диярлек артып, 1 миллиард долларга җиткән.

Виктор Орбан Рөстәм Миңнехановка Будапештка килгәне өчен рәхмәт әйтте.

– Бу – безнең өчен зур хөрмәт билгесе, – диде Венгрия Премьер-министры. – Безнең илдә – бәйрәм һәм без аны дусларыбыз белән бергә бәйрәм итәргә яратабыз.

Сөйләшү барышында Виктор Орбан Татарстанга соңгы эш визитын да искә алды. Ул Казанның кунакчыллыгын югары бәяләде. Билгеле булганча, ике арада тәүге хөкүмәтара хезмәттәшлек турында килешү 1992 елда ук имзаланган. Венгрия Премьер-министрының матбугат сәркатибе Берталан Хаваши сүзләренә караганда, очрашу барышында яклар хезмәттәшлекне, шул исәптән авыл хуҗалыгы өлкәсендә дә дәвам иттерү турында фикер алышкан. «Санкцияләргә һәм сәяси кыенлыкларга да карамастан, Россиядәге Венгрия компанияләре эшне җәелдерү мөмкинлекләрен эзли», – дип, матбугат сәркатибенең сүзләрен китергән Венгрия басмалары.

Сербия Босниясе һәм Герцеговина Республикасы Президенты Милорад Додик белән очрашу барышында Татарстан Рәисе ике республиканың үзара охшашлыгын да билгеләп үтте. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан белән Босния һәм Герцеговина территорияләре һәм халкы буенча, аерым алганда, конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә бер-берсенә бик якын. Әлеге илдә яшәүчеләрнең күпчелеге сөнни мәзһәбендәге ислам динен һәм православие динен тота, шул ук вакытта католиклар, протестантлар, иудаизм динен тотучылар һәм башка конфессияләр дә бар.

Милорад Додик пандемия аркасында иртәрәк очрашырга насыйп булмавын да әйтте.

– Без сезне күрүебезгә бик шат. Пандемия аркасында Татарстанга бара алмадык. Әмма сезнең монда килүегезне ишетүгә, очрашырга булдык, – диде Президент.

Милорад Додик сүзләренә караганда, Босния һәм Герцеговина Россиягә каршы санкцияләр кертүне хупламый. Ул Россия Президенты белән күп тапкыр очрашуын һәм Владимир Путинны хөрмәт итүен дә әйтте.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

realnoevremya.ru

Михаил ШӘРИПОВ, Татарстан рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясе идарәсе рәисе:

Бүген республикадагы туклану оешмаларында пешекчеләр җитми, шуңа күрә һәр белгеч алтын бәясенә тора. Бер яктан караганда, бу яхшы, чөнки яхшы эшчеләрне югалтмас өчен, аларга тиешле шартлар тудырырга тырышалар. Мәсьәләне хәл итү өчен, яшьләрдә һөнәргә карата кызыксыну уятырга кирәк.

(«Реальное время» басмасыннан)

РОССИЯДӘ – СӨТ ҖИТЕШТЕРҮ

Россиядә сөтнең 61 процентын авыл хуҗалыгы оешмалары, 31 процентын хуҗалыклар, 8 процентын шәхси эшмәкәрләр җитештерә.

ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН:

2023 елның 1 нче яртысында >> **16,6 млн тонна**

Былтыргы күрсәткечтән **0,5 тонна**га күбрәк

*Росстат мәгълүматларына нигезләнеп



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БАНКРОТЛЫК ТҮГЕЛ, ӘММА ШУҢА ЯКЫН

Дөнья икътисадында турбулентлык дәвам итә һәм көчәя. Энергетик кризис яңадан ишек шакый. Бразилия көтмәгәндә утсыз калды. Берьюлы барлык штатларда диярлек өзелде ут. Бу шулкадәр көтелмәгәндә булды: Баия штаты башкаласында метро пассажирларны юллар буйлап тәпиләргә туры килде. Бар шәһәрләрдә диярлек светофорлар сүнде. Рәсми хакимиятләр бләкаутның сәбәбен әйтә алмады. Калифорниядә, мәсәлән, гадәттән тыш югары температура сәбәпле ут өзелде. Башка илләрдә дә җәйге кызулык электр энергиясен чиктән тыш күп кулланугa китерә һәм аварияләр еш була.

Австралиянең газ эшкәртү заводларында забастовка ихтималы арта. Газ экспортлаучы төп илләрнең берсе экспортны туктатыр дип курку Европада зәңгәр ягулык бәясен өскә күтәрде. Дөрес, бәяләр 2022 елдагы кебек үк түгел, әмма барыбер югары.

Азиянең нефть эшкәртү заводларында – җир мае кытлыгы. Бу Кувейтта яңа зур нефть эшкәртү заводы сафка басуга бәйле. Әлеге гарәп иле чи нефть сатуны нык киметеп, Европага нефть продуктлары сатуга күчте. Согуд Гарәбстанында нефть чыгаруны кимету белән туры килеп, эшкәртүче заводлар нефть ачлыгы кичерә башлады. Болар барысы да – хәл ителә торган проблемалар. Нигездә валюталарга ышаныч булмаганга шулай килеп чыга. Белгечләр дөньяда дизель ягулыгы дефициты да күзәтелә дип әйтә. Россиядә дә үзен сиздерә ул: биржа бәяләре күтәрелә, ягулык җитми.

Дөньяның иң зур банкларыннан берсе булган JP Morgan Үзәк банкларның Американың озак сроклы облигацияләрен сатып алудан туктауларын хәбәр итә. АКШ Хөкүмәтенең бары тик әҗәт кәгазьләре сату хисабына гына диярлек яшәвен искә алсак, бу – американнар өчен зур проблема. Кытайның исә үз кайгысы: эре дәүләт банклары күпләп доллар сата. Бу юаньның курсын тотып тору өчен эшләнә. Иң эре төзелеш компаниясе Evergrande Нью-Йорк судына банкротлык турында гариза бирде дигән хәбәр үткән атна ахырында зур финанс дулкынлануы тудыра язды. Evergrande компаниясенең түли алмаслык әҗәтләр астында калуын без ике елга якын язабыз инде. Компания бары тик Кытай Үзәк банкы акчасы хисабына яшәвен дәвам иттерә. Әмма әлегә сүз банкротлык турында бармый. Evergrande офшор бурычларын реструктурлау буенча гына үтенеч юллаган. Бу да хәлнең шәп булмавыннан килеп чыга. Кытайның тагын бер девелоперы Country Gardens бурычларын түли алмый, әмма рәсми Пекин бернинди дә кризис түгел дип аңлатырга тырыша. Финанс аналитиклары Кытай икътисадындагы хәл уңаеннан борчылу белдерә.

Россиядә

«ЛУНА – 25»: ӨМЕТЛӘР ӨЗЕЛМӘСЕН

Россиянең мәгълүмат кырында да күңелсез хәбәрләр күңелләребезнең күбрәк. Шөкер, сумның девальвациясе тукталды. Мәскәү, доллар бәясе йөздән арткач, социаль киеренкелекнең шартлау ноктасына якынаячагын яхшы аңлады. Сум – доллар атынчыгы дәвам итәр иткән, әмма аны билгеле бер кыса эчендә тотарга тырышырлар. Һиндстан Россия бодаен долларга сатып алырга тели, тик бик зур ташлама белән. Дисконт бер тоннага 40 долларга кадәр җитәр, диләр. Банк даирәләрендә Һиндстан Россияне 40 миллиард долларга якын акчага «чөйдә» дигән хәбәрләр таралды. Нефтьне арзанга һәм рупияләргә саткан нефтьчеләр акчаларын илгә кайтара алмый. 39 миллиард долларга тиң акча Һинд банкларында эленеп калган, чөнки илнең Үзәк банкы милли валютаның Һиндстаннан читтә кулланылуын рөхсәт итми. Проблемаы дәүләтара килешүләр аша хәл итәрләр итүен, әмма валюта бүген үк кирәк.

Россия патриотик җәмәгатьчелеге «Луна – 25» миссиясенең һәлакәт белән тәгәлләнүе уңаеннан тирән дулкынланды. Дөресен генә әйткәндә, кайчандыр айдәп баручы держава булган ил соңгы еларда галәмара узышның аутсайдерына әверелде. «Роскосмос» технологик уңышлардан бигрәк, караклык масштаблы буенча рекордлар куйды. Бу – рәсми факт, аннан беркая да китеп булмый. «Луна – 25» аппаратының Айның беразу дә аяк басмаган өлешенә төшеп утырып, шуннан җиргә мәгълүмат тапшыра башлавын ватанпәрвәрлеге чиктән тыш кайнаган һәркем өзелеп көтте. Әммa юкка. Илнең аякка басуының бер символы булырга тиешле аппарат Ай туфрагы белән очрашуга, тынсыз калды, югалды. Техник чишелешне исәпләүдә хата китүе генә мәгълүм. 18 ел буе эшләнеп, 6 миллиард сумга төшкән проект шулай итеп Ай туфрагында күмелде. Моны ишетеп, галәм проектларының гыйльми җитәкчесе булган 90 яшьлек академик Михаил Маров хастаханәгә эләкте, Ай программасына булган соңгы өмете өзелүен әйтте, диделәр. «Луна – 24» аппаратының Җир иярчененә төшеп утырып, 170 грамм Ай туфрагын алып кайтуына ярты гасырга якын вакыт узды шул инде. Аннан соң берничә дәүләт Айны тикшерүгә үзләреннән өлеш кертте, Россия – юк.

Өметне өзәргә ярамый. 2027 елда «Луна – 26» аппараты очышка әзерләнә, диләр. «Эшләмәгән кеше генә ялгышмый», ялгышлар кабатланса гына начар.

ДУСЛАР ҖЫЕЛГАН ҖИРДӘ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Будапештта Рөстәм Миңнеханов илдә узучы Җиңел атлетика буенча XIX дөнья чемпионатында да катнашты. Әлеге чарага Венгриянең милли бәйрәме уңаеннан тантаналарда катнашучы хөрмәтле кунаклар чакырылган иде. Шул форсаттан, Татарстан Рәисе Төрекмәнстан Президенты Сердар Бердымөхәммәтов белән дә очрашты. Яклар делегацияләрнең чираттагы эш визитлары турында фикер алышты.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Фикер

Владимир КУТИЛОВ, сәяси киңәшче, «Теория Дарвина» агентлыгы генераль директоры:
– Венгриягә эш визиты Татарстан Рәисенең халыкара мөнәсәбәтләр һәм илнең тышкы сәясәте өлкәсендәге үзенчәлекле статусын тагын бер кат күрсәтте. Рөстәм Миңнехановның чит илдәге партнерларыбыз белән элемтәләр урнаштыру һәм нәтиҗәле икътисадый хезмәттәшлек коруда зур тәҗрибәсе булу белән беррәттән, аңа халыкара мәйданда ислам илләре белән мөнәсәбәтләр җайлау бурычы да йөкләнгән. Быелгы «KazanForum» бу эшнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын һәм мөселман илләре белән элемтәләр урнаштыруда Татарстанның тоткан урынын раслады инде. Венгриядәге рәсми чараларда катнашучылар исемлеге үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Республикага ислам илләре, дөнья күләмендә игътибарга лаек булган Катар, Төркия, Согуд Гарәбстаны, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре кебек илләр белән нәтиҗәле, озак вакытка исәпләнгән, тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыру мөһим. Мондый халыкара хезмәттәшлек инвестицияләр җәлеп итү, алдынгы технологияләр өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу, уртак сәнәгатьләрне үстерү өчен дә, икътисадый, мәдәни, социаль элемтәләрне ныгыту юнәлешендә дә яңа мөмкинлекләр ача. Гомумән алганда, Рөстәм Миңнеханов – төбәк башлыклары арасында илнең тышкы сәясәтендә катнашырга компетенциясе һәм хокукы булган сирәк җитәкчеләрнең берсе. Бүгенге шартларда Татарстан Рәисенең халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге бай тәҗрибәсе аеруча да мөһим. Чөнки ил җитәкчеләре арасында гына түгел, ә төбәкләр дәрәҗәсендә, аерым тармакларга бәйле рәвештә ныклы элемтәләр булдырырга кирәк.

Виктор СИДОРОВ, Казан (Идел буе) федераль университетының политология кафедрасы доценты, сәяси фәннәр кандидаты:
– Бүгенге кебек катлаулы шартларда чит илләр белән сөйләшүләр алып бару өчен Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов күп яктан компромисс фигура булып тора. Аңлашыла ки, билгеле сәбәпләр аркасында федераль дәрәҗәдә Европага юл ябык. Украина тирәсендә низаг дәвам итә. Ә Татарстанга Көнчыгыш белән уртак тел табу, гомумән дә, алар белән элемтәләр җайлау җиңелрәк. Рөстәм Миңнеханов – төбәк дәрәҗәсендәге, нейтраль, әмма мәдәни яктан Көнчыгышка якын фигура. Татарстан өчен бу файдага гына. Димәк, без – ил күләмендә әһәмиятле төбәк. Республиканың мәдәниятен, Көнчыгыш, гарәп илләре белән элемтәләр җайлау мөмкинлекләрен югары бәялиләр. Татарстан моннан отачак кына. Будапешттагы рәсми очрашуларга килгәндә, безнең төп партнерыбыз Төркия икәне аңлашыла, әлбәттә. Әлеге ил аша башка илләрне үзебезгә карату мөмкинлеге зуррак. Татарстан аша сәяси яктан да, икътисадый яктан да Көнбатышныкы булмаган илләргә ишекләр ачыла. Бүген без Көнчыгышка таба борылу турында сүз алып барабыз икән, моны республикадан башка эшләү катлаулырак та, кыенрак та, чыгымлырак та булачак. Чөнки Татарстанны ислам дөньясында беләләр. Ничек кенә булмасын, без Көнчыгыш илләре белән элемтәләр урнаштыру өчен мәдәни ишекләр булып торабыз.

ИМИНЛЕК ҺӘМ ТУГРЫЛЫК БИЛГЕСЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Россия Федерациясе Дәүләт флагы көне белән котлавы

Кадерле татарстанлылар! Сезне 22 августта билгеләп үтелә торган Россия Федерациясе Дәүләт флагы көне белән котлыйм.

Дәүләт флагы илкүләм символ гына түгел. Ватанпәрвәрлек һәм тынычлыкны, ышаныч һәм иминлекне, антка тугрылыкны һәм рухи гореф-гадәтләрнең ныклыгы идеяләрен берләштерүне чагылдырган ак-зәңгәр-кызыл аләм күпмилләте Россия халкын дәүләтчелекне һәм мөстәкыйль мәнфәгатьләрне яклау, буыннар эзлеклелеген тәэмин итү һәм бай мәдәни мирасны саклау, халыкара аренада тигез хокуклы һәм нәтиҗәле хезмәттәшлеккә корылган мөнәсәбәтләр булдыру юнәлешендә берләштерүче көч булып тора.

Хәзерге катлаулы шартларда без үзләренең фидакарь хезмәтләре һәм хәрби батырлыклары белән Ватаныбызның бөеклеген һәм данын арттыручы ата-бабаларыбызның истәлегенә тагын да лаеклырак булырга тиеш. Уртак йортыбызның бүгенгесе һәм киләчәге нинди буласы нәкъ менә бездән тора. Илнең төп атрибутларына – Флагка, Гербка һәм Гимнга – ихтирам күрсәтеп, шул хисләрне балаларга һәм оныкларга тапшырып, без яшь буында гражданлык, олы һәм кече Ватанга, Конституциягә, дәүләт символларына, туган телгә, тарихка, мәдәниятко, табигатькә дөрес мөнәсәбәт, республика өчен горурлык тәрбиялибез. Әлеге гадәттән тыш мөһим ориентирлар Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән, федераль һәм республика законнарында һәм программаларында чагылыш тапкан.

Барыгызга да эшегездә уңышлар, тынычлык һәм иминлек телим. Иксез-чиксез зур Ватаныбызның һәр төбәгендә Россия Дәүләт флагы астында ирек һәм хакыйкать тантана итсен!

Бәйрәм белән, хөрмәтле ватандашлар!

КОТЛЫЙБЫЗ!

Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Совет районының «Район торак идарәсе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Поливин** Александр Васильевичка **Россия Федерациясе Президенты Указы белән «Россия Федерациясенең атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Ветеринария өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш ветеринария табибы **Аббазов** Мидхәт Мирвәт улына **Россия Федерациясе Президенты Указы белән «Россия Федерациясенең атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Соравыңа җавап ал

«Кайнар линия»

Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе Татарстанның Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле белән берлектә «кайнар линия»дә халыкның зарларын тыңлады.

Дүрт сәгатьлек аралашу вакытында 32 сорау белән мөрәҗәгать иттеләр. Сорауларның төрлесе бар. Берәүләр баласын бакчага урнаштыра алмый, икенчеләрнең беренче сыйныфка баручы сабыена мәктәптә урын калмаган. Кыскасы, мәктәпләр җитми! «Кайнар линия»дә катнашкан Дәүләт Советы депутаты Татьяна Ларионова әнә шулай ди. Аны бигрәк тә Казан янындагы бистәдә яшәүчеләр язмышы борчый.

– Без июнь аенда мондый бер «кайнар линия» оештырган идек. Монысы – җәй буена әлеге сораулар хәл ителгәнме, үзгәрешләр булганмы, шуны да белешү иде, – ди Татьяна Ларионова. – Сораулар арасында Лаеш, Питрәч, Биектау районнарында яшәүчеләрдән зарлар күп. Төзелешләр бара, йортлар салына. Ә менә мәктәпләр җитми. Ул җирлектәге мәктәптә урын калмаса, башка авылларга йөртеп укытыр өчен мөмкинлекләр табыла. Август конференциясендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та, социаль объектларны салуны истә тотарга кирәк, дигән иде.

Мөрәҗәгатьләр арасында авыру балаларын да башкалар укыган мәктәптә укытасы килеп шалтыраткан әти-әниләр дә бар икән. Татьяна Ларионова бу мәсьәләне үз контроленә алырга вәгъдә бирде.

Берәү дә баланы мәктәпкә әзерләргә булышуны үтенеп шалтыратмаган. Депутатлар моңа шат. Димәк, республикада «Мәктәпкә әзерләнергә ярдәм ит!» акциясе җиренә җиткереп башкарыла. Исемлеккә кергән барлык бала да үзенә тиешле рюкзак һәм уку кирәк-ярагын алган.

Татарстанның Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская берничә шалтырату буенча тикшерү дә уздырачакларын әйтте.

– Бер әни шалтыратты. Аның баласын беренче сыйныфка алмыйча кире борганнар, ә инде аннан соң килгән өч баланы кабул иткәннәр. Без бу мөрәҗәгатьнең дөреслеген тикшерәчәкбез. Шулай ук баласы көллияткә укырга керә алмаган әни дә элемтәгә керде. Укырга керер өчен балага җитмәгән, ә инде 10 нчыга барып, аттестат алмау ихтималы да бар икән. Без мондый очракларда балага булышу юлларын табабыз. Көллияткә барып сөйләшәбез, бу укучы укый алырлык юнәлешне табып, аңа ярдәм итәбез, – ди Сәрия Сабурская.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Урып-җыю – 2023

БӘРӘКӘТЛЕ ЧОР

Урып-җыю кампаниясе акрынлап ахырына якынлаша. 21 августка булган мәгълүматлар буенча, барлык чәчүлек мәйданнарының 82 процентында ашлык сукты-рылган. Әлеге вакытта амбарларга 3 млн 223 мең тонна икмәк кайтарылган.

Инде бөртеклеләрне җыеп тәмамлаучылар да бар. Беренчеләр рәтендә – Әтнә һәм Зәй районнары. Якын арада Кама Тамагы һәм Саба районнары аграрийлары да эшләрен тәгәлләячәк. Ә менә уңдырышлылык буенча әлегә Тәтеш районын куып тота алучылар юк. Әлеге район игенчеләре гектарыннан 40 центнерга якын уңыш җыеп алуга ирешкән. Аннан кала уңышның чыгышы буенча лидер районнар булып Кайбыч, Кама Тамагы һәм Чүпрәле, Балтач, Спас һәм Лаеш районнары санала. Гомумән алганда, республика буенча уртача уңдырышлылык гектарыннан 26,2 центнерны тәшкил итә.

– Әйе, безнең район уңдырышлылык буенча алдынгылар рәтендә, тик әгәр барлык хуҗалыклар да бөтен мөмкинлекләрне файдаланып эшләсә, тагын да зуррак уңышка ирешә алыр идек. Шуңа күрә без әле нәтиҗәдән тулысынча канәгать, дип әйтә алмыйбыз, – диде Тәтеш районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ирек Садриев. – Гектарыннан – 60–70 центнер алучы хуҗалыклар да, 20 центнер гына алганнары да бар. Югыйса барысында да бер үк вакытта кояш чыга, кояш бата, бер үк төрле мөмкинлекләр бирелә. Бөтен уңышсызлыкны һава торышына сылтамыйча, һәр технология җиренә җиткерелеп башкарылса, нәтиҗәсе күпкә яхшырак булыр иде.

Ирек Садриев әйтүенчә, хуҗалыкларга минераль ашламалар кертү буенча да тырышыбрак эшләргә кирәк. Әлеге вакытта район барлык мәйданнарының 91 процентыннан 165 мең тонна ашлык җыеп алынган.

– 3 нче һәм 4 нче класс ашлык сату бәяләре әлегә билгеле түгел. Узган елгыдан да түбәнрәк булмас, дип өметләнәбез, – диде ул.

Узган шимбәдә Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә ТР Премьер-министры урынбасары – ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров та урып-җыю буенча хисап тотты. Аның сүзләренчә, республикада кыр эшләре дәвам итә, уңыш җыю белән параллель рәвештә көзге культуралар чәчү, туфрак эшкәртү һәм азык әзерләү бара. Гомумән алганда, республикада 4 мең гектар борчак, 62 мең гектар арпа һәм 17 мең гектар көзге бодай җыеп алынмаган, алар бүген үк 20 процентка кадәр югалтулар кичерә.

Республиканың алты районында бәрәңге уңышын җыеп алуга да керешүгә районнар бар. Алар – Арча, Буа, Лаеш, Минзәлә, Түбән Кама һәм Чистай. Әлегә икенче икмәк 150 мең гектарга якын мәйданда казылган, уртача уңыш гектарыннан 295 центнер тора. Министр азык әзерләү турында да әйтеп узды. Билгеле булганча, җәй башында бик күп районнарда диярлек авырлык бар иде. Хәзер күпчелек районнарда вазгыять яхшы, ә менә иң аз азык Әлки, Алексеевск, Югары Ослан һәм Чирмешән районнарында әзерләнгән. Шәхси хуҗалыклар өчен дә азык әзерләү дәвам итә. Бүген 738,9 мең тонна печән хәстәрләнгән, ягъни бу – ихтыяҗның 90 проценты. Бу мәсьәләдә Яңа Чишмә, Әлмәт, Минзәлә районнарында да авырлык бар.

Зөһрә САДЫЙКОВА



Идар Мөхәммәтҗанов

УҢДЫРЫШЛЫЛЫК БУЕНЧА ЛИДЕР РАЙОННАР

Районнар	Суктырылган мәйданнар (гектар)	Җыеп алынган ашлык (мең тонна)	Уңдырышлылык
Тәтеш	40 562	161,7	39,9
Кайбыч	24793	88,1	35,5
Кама Тамагы	25088	88,9	35,5
Чүпрәле	29161	113,2	38,8
Балтач	26246	88,4	33,7
Спас	39137	128,1	32,7
Лаеш	16521	53,8	32,5
Мамадыш	34837	106,6	30,6

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 21 августка мәгълүматлары

НИЯЗ ХӘЛИУЛЛИН: «КИЛӘСЕ БИШ ЕЛНЫ ИМПОРТ АЛМАШТЫРУ ЭШЕНӘ САРЫФ ИТӘЧӘКБЕЗ»

Kazan Digital Week – 2023

Эш барышын компьютер көйли, мәгълүматны ясалма интеллект саклый, сыерларны робот сава. Авыл хуҗалыгындагы хәзерге чынбарлык шундыйрак.

Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге (РИВЦ) генераль директоры Нияз ХӘЛИУЛЛИН белән дә сүзебез авыл хуҗалыгы тармагы, агросәнәгать комплексындагы цифрлаштыру һәм санлы киләчәгебез турында барды.

:: Авыл хуҗалыгы, агросәнәгать комплексы – шактый консерватив тармаклар. Бу юнәлешләрдә цифрлы технологияләр ни дәрәҗәдә кулланыла? Аграрийлар цифрлы технологияләргә акча җәлеп итәргә ризамы?

– Риза, һәм җәлеп итә дә! Кемнәр моңа акча җәлләми, алар нәтиҗәлерәк эшли. Бу кирәк түгел, дип уйлаучылар азая. Алар йә базардан китә, йә күршеләренә карап үзгәрә. Экспериментлардан курыкмый торган җитәкчеләр ота. Консерватизм хакимлек итәргә тиеш түгел.

:: Хәзер цифрлаштыру өлкәсендә нинди тренд бара?

– Мәгълүмат (данные), ясалма интеллект. Бу – модага яраклашу түгел. Ә хәзерге вазгыятьтәге мәҗбүри чара. Мәгълүмат саклау дигәндә, дәүләт секторын күз уңында тотам. Бу актуаль.

:: Авыл хуҗалыгы, агросәнәгать комплексында нинди замана технологияләре инде хәзердән үк кулланыла?

– Терлекчелек тармагында роботлаштыру бара, бу юнәлеш автоматлаштырылган. Әлбәттә, ул импортка да нык бәйле. Фаразлау системасы үсештә. Әйтик, мәгълүматны анализлау, космомониторинг, исәп-хисап алып бару (учёт), идарә итү, контроль системалары. Әлбәттә, консерватив юнәлешне сайлаган хуҗалыклар да юк түгел. Мәсәлән, кечкенә генә гаилә фермалары. Әйтик, аларда иң гадәти саналган цифрлы исәп-хисап алып бару системасы да юк. Әлбәттә, аларны моның өчен сүгәргә кирәкми. Алар яраткан эшләре белән үзләре теләгәнчә шөгыльләнә. Зур бизнес, әлбәттә, алдарак әйтеп үткән цифрлы мөмкинлекләрдән файдалана.

:: Әгәр фантазиягә бирелеп, «5 елдан соң ни булыр?» дигән сорауга җавап эзләп карасак...

– Кискен үзгәрешләр көтәргә кирәкми. Без бу елларны импорт алмаштыру эшенә сарыф итәчәкбез. Хәзер кризис чоры. Даими рәвештә инвестицияләр кертеп торганнар гына үсештә кала. Бу очракта сүз технологияләр турында гына түгел, үсеш, команда, җир турында бара. Авыл хуҗалыгына бизнес буларак карамаган кешеләргә авыррак булачак, әлбәттә. Бәхеткәме, Татарстанда нәтиҗәле булмаган бизнес вәкилләре бик аз.

Минемчә, берничә елдан күпләр электрон сәүдәгә күчәр. Пандемия безне – физик затларны – товар һәм хезмәтләрне электрон сәүдә аша табарга һәм сатып алырга өйрәтте. Минемчә, биш елдан соң бизнес та моңа гадәтләнәчәк.

:: Без сезнең белән сентябрьдә узачак «Kazan Digital Week – 2023» халыкара форумы алдыннан очрашабыз. Әзерлек ничек бара? Быел нәрсәләр тәкъдим итәргә җыенасыз?

– Әзерлек бара. Безнең инде тәҗрибә дә юк түгел. Проектларга килгәндә, Дәүләт мәгълүмати системасын (ГИС) тәкъдим итәргә җыенабыз. Аны башка төбәкләргә дә кызыклы итеп җәелдерәсе килә. Моннан тыш, геомәгълүмати системалар, хайваннарның цифрлы паспорты кебек проектларга бәйле яңалыклар булыр дип уйлыйм. Бу – күргәзмә өлеше. Эшлекле программага килгәндә, федераль һәм бизнес өчен мөһим булган көн кадагында торган актуаль мәсьәләләр буенча фикер алышу булачак. Мисал өчен, мәгълүмати куркынычсызлык. Бизнеска килсәк, авыл хуҗалыгы тармагы компанияләре, авыл хуҗалыгы юнәлешендәге җитештерүчеләр белән тәҗрибә алмашу, уй-ниятләр белән уртаклашу. Төбәкара тәҗрибә алмашу да булачак. Татарстан тәҗрибәсе башкаларга бик кызыклы.

:: Форумның үзенчәлеге нәрсәдә дип уйлыйсыз?

– Замана теле белән әйткәндә, бу – нетворкинг (файдалы элемтәләр). Уйлап табучылар, бизнес вәкилләре, дәүләт белән очрашу урыны. Быел форумга аграрийларны да чакырырга уйлыйбыз. Былтыр холдинглар да катнашты. Татарстаннан гына түгел, Россия күләмендәге зур холдинглар да килде. Шушы мәйданчыкта еш кына уртак идеяләр, проектлар барлыкка килә. Бу киләчәктә кайбер сорауларны хәл итәргә булыша. Ничә ел инде форумга бәйле яхшы кайтавазлар гына ишетәбез. Әлбәттә, чит илдән дә катнашучылар булсын иде. Татарстандагы проектлар төбәк яисә Россия эчендә генә калмасын иде. Аларны да чит ил базарына чыгарырга кирәк. Әйтик, гарәп илләре үсештә, алар белән элемтәләр ныгытып булыр иде. Үз проектларыбызны гамәлгә ашыру җәһәтеннән гарәп илләре кызыклы.

:: Аграрийларны да чакырабыз, дидегез. Ниндидер сайлап алу булачакмы?

– Сайлап алу булмаячак. Барысын да чакырабыз. Кем моны үзе өчен кызыклы дип таба, шул килә. Тәҗрибәдән күренгәнчә, мондый төр форумнарга, гадәттә, бер үк кешеләр килә. Кемнәр зарланып, «барысы да начар» ди икән, алар инде пассив. «Монысын да узарбыз», – дип, кризиска карамастан үсеш юлында булганнарны исә бөтен чараларда да күрергә була. Алар яңа мәгълүмат туплый, мөмкинлекләр эзли.

Әңгәмәдәш – Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

СУ АСТЫНДА НИЛӘР БАР?

Әгәр эзли башласаң, ни генә тапмассың. Татарстан сулыклары бик «бай». Иске тәгәрмәч, полиэтилен капчык, шешә һәм тагын әллә нинди чүпләр табарга була аннан. Баксаң, су төпләрендә озак еллар тик ятучы торбалар да бар икән. Монысының инде зыяны да күп, мәшәкате дә зур.

Сулыклардагы торбалар турында елга нәтиҗә ясаган очрашуда Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков та сөйләгән иде. Алга куелган максат инде 60 процентка үтәлгән. Шушы көннәрдә журналистлар Түбән Кама сусаклагычында 23 километрга сузылган нефть торбаларын ничек итеп су өстенә чыгаруларын күреп кайтты. Аның 13 километрында эшләр төгәлләнгән инде. Моның өчен без Чулман елгасының Менделеевск районы Бизәкә авылы янәшәсендәге өлешенә кузгалдык.

Без килгәндә эшнең кызган вакыты иде. Биредә вахта ысулы белән эшлиләр. Барлыгы 30 кеше хезмәт куя. «Ядран-Строй» подрядчы оешмасының баш инженеры Марат Таран әйтүенчә, бүгенгә су астындагы торбаларның яртысыннан артыгын чыгарганнар инде. Җиңел эш түгел, ди җитәкче.

– Узган елның декабрендә эшкә керештек. Быел нәкъ шул вакытка торбаларны чыгарып та бетерәчәкбез. Алар бик иске. 50 елдан артык су төбендә ятканнар. Торбаларны кисеп чыгарабыз. Моның өчен башта су астында эшләрлек мөмкинлек тудырыла. Водолазлар эшчеләр өчен эш урыны булдыра. Аннары хезмәткәрләребез торбаларны 10ар метр итеп кисә. Шуннан соң алар өскә чыгарыла. Бу торбаларны махсус урында утильләштерәбез, – ди Марат Таран. – Торбалар бик иске, эчләрендә нефть калдыклары да бар. Шунлыктан без бик сак эшлибез. Суга пычрак төшмәсен өчен, ачык өлешләрен каплап, өскә күтәрәбез.

Әлеге эшләр «Экология» илкүләм проектының «Иделне савыктыру» программасы ярдәме белән башкарыла. Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Егор Тарнавский әйтүенчә, торбаларны судан чыгару Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме һәм Россия Табигать министрлыгы белән берлектә башкарыла.

– Түбән Кама сусаклагычында яраксыз торбалар күп еллар элек су күтәрелгәндә аста калганнар. Начар торбалар Иделгә генә түгел, халык өчен дә куркыныч иде. Ни дисәк тә, бу сусаклагыч аша 1 миллионга якын кеше су белән тәэмин ителә, – ди Егор Тарнавский. – Чулманнан аста «Турай» һәм «Белоус» су станцияләре урнашкан. Алар аша куллану һәм эчәр өчен Чаллы, Түбән Кама, Менделеевск, Алабуга районнарында яшәүчеләргә су бара. Бер җирдә яткан торбалар күпме елгага зыян сала. Аларны судан чыгару эше 2016 елда башланган иде. Башта документлары әзерләнде, аннан күпмегә төшәсе билгеләнде. 2021 елда Россия Табигать министрлыгы аша бу эшләрне башкару өчен субсидия алуга ирештек. Бу торбалар судан чыгарылып беткәч, республика халкы суның яхшыруын сизәчәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

2023 елда «Экология» илкүләм проекты өчен 3372,6 миллион сум акча бүленеп бирелгән. Шуның 2670,3 миллион сумы – Россия бюджетыннан, калганы Татарстан акчасы.

Сулыкларны торбалардан арындыру **930** миллион сумга төшәчәк. Шуның **200** миллион сумы – «РИТЭК» оешмасы акчасы. Әлеге проект Россиядә беренче тапкыр башкарыла. Моңа кадәр бер җирдә дә сулыклардагы торбаларны чыгаручылар булмаган. Татарстан тәҗрибәсеннән соң ул башка өлкәләрдә дә кулланыла башлаячак.

«Экология» илкүләм проекты ярдәме белән республикада башкарылучы эшләр

«Иделне савыктыру» проекты
Ул Иделгә агучы пычрак суларны киметү өчен биологик чистарту корылмалары төзү, Иделгә күп еллар зыян салучы объектларны юкка чыгару проектларын үз эченә ала. Шулай ук ләм басуларын рекультивацияләү дә, сулыклардагы тик яткан торбаларны чыгару эшләре дә шушы проект ярдәмендә башкарыла.

«Чиста ил» федераль проекты
Аның ярдәмендә Казанда Самосырово полигонын рекультивациялиләр. Андагы эшләр дә ел ахырына тәмамланыр дип көтелә.

«Уникаль сулыкларны саклау» проекты
Әлеге проект ярдәмендә Мамадыш районындагы Бөрсет елгасын чистарталар. Ул да ел ахырына төгәлләнәчәк.

«Урманнарны саклау» проекты
Бу проект урманны саклауга багышланган. Аның ярдәмендә орлыклар җитештерү, агач утырту, янгынга каршы махсус техникалар белән тәэмин итү кебек эшләр башкарыла.

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ һӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ һӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ һӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР һӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы, республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсенең гомуми бүлеге мөдире урынбасары – беркетмә секторы мөдире **Сираҗиева** Гөлшат Дилшат кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш кертүләре өчен Бөек Ватан сугышында катнашучы **Лыкова** Валентина Лукьяновна; Бөек Ватан сугышында катнашучы **Моисеева** Анна Ивановна; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Ситдыйков** Равил Сәхиб улы; **Хубахов** Николай Геннадиевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Фәйзуллин** Равил Абдрахман улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың төзелеш тармагын үстерүгә өлеш кертүе өчен«Портал» төзелеш-монтажлау предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Әхмәтгәрәев** Булат Ринат улына; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың нефть химиясе сәнәгатен үстерүгә өлеш кертүе өчен «Аммоний» акционер җәмгыяте техник контроль бүлегенең куертылмаган азот кислотасы җитештерү цехы лабораториясе продукциянең һәм технологик процессның сыйфатын тикшерүчесе **Илдерханова** Эльвира Миңнехан кызына; күпьеллык намуслы хезмәтләре һәм республиканың сәнәгать комплексын үстерүгә өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары **Карпов** Родион Михайловичка; «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте бәяләр кую идарәсенең бәяләрне контрольдә тоту бюросы башлыгы **Пастернак** Ирина Александровнага; «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте сыйфатны тикшерү идарәсенең хезмәт нормаларын билгеләү буенча инженеры **Тарасова** Галина Алексеевнага; дәүләт техник күзәтчелеге системасын үстерүдәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы буенча бүлеге башлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге баш дәүләт инженер-инспекторы **Мөхәммәтҗанов** Мансур Мөнир улына; сатыла торган алкогольле продукциянең сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итүгә, республиканың кулланучылар базарында хокук бозуларны кисәтүгә өлеш кертүе өчен Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе оператив муниципальара контроль бүлеге башлыгы **Романов** Павел Николаевичка; Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе Казан территориаль органының контроль-инспекция бүлеге башлыгы **Хәкимова** Нәфисә Яхъя кызына; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың нефть химиясе сәнәгатен үстерүгә өлеш кертүе өчен «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәтенең технологик җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү хезмәте өлкән мастеры **Сәлахов** Илдар Искәндәр улына; күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм мәдәниятне үстерүгә өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Никольское урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең технология һәм башлангыч сыйныфлар укытучысы **Аверьянова** Тамара Николаевнага; Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы һәм Лаеш шәһәренең «Район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең 16 номерлы филиалы – Никольское авылы мәдәният йорты режиссеры (хормейстеры, балетмейстеры) **Германова** Галина Михайловнага; «Я.Е. Емельянов исемендәге мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең мәгълүмати-методик тәэминат бүлеге мөдире **Муллина** Ирина Айдар кызына; күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә өлеш кертүләре өчен «Содружество» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты **Ивлев** Сергей Александровичка; «Кама аръягы-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы **Шәрәфетдинов** Артур Эдуард улына; күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм республиканың төзелеш тармагын үстерүгә өлеш кертүләре өчен «Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 24 номерлы калыпка салу цехы башлыгы **Минһаҗев** Фәрит Рәшит улына; Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы урынбасары **Нигматуллин** Эдуард Валерьевичка; Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Хокукый эш һәм өлешле төзелешне контрольдә тоту идарәсе башлыгы **Рәимов** Шамил Надир улына; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, ветераннар хәрәкәтен үстерү буенча актив иҗтимагый эшчәнлеге һәм яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди башлангыч ветераннар оешмасы рәисе **Романова** Валентина Ивановнага; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә өлеш кертүе өчен «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты, әйдәүче сәхнә остасы **Сафин** Нуриәхмәт Вәлиәхмәт улына; республиканың азык-төлек сәнәгатен үстерүдәге казанышлары һәм халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен **«Эссен Продакшн АГ» акционер җәмгыяте коллективына**; спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүләре, республикада физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен «Татарстан Республикасының Ядрә белән ату һәм стендка ату федерациясе» төбәк спорт иҗтимагый оешмасы вице-президенты **Бәдретдинов** Альберт Әнис улына, «Стендка ату һәм ядрә белән ату буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тренеры **Лузганова** Екатерина Павловнага, «Стендка ату һәм ядрә белән ату буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе филиалы тренеры **Филиппов** Виктор Ивановичка; намуслы хезмәтләре һәм җәмәгать хокук тәртибен тәэмин итүгә өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының махсус техник чаралар бюросы 7 бүлеге башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Бәдретдинов** Искәндәр Наил улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту бүлекчәсе өлкән оперуполномоченные, полиция майоры **Нурмөхәммәтов** Вадим Назиф улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы баш тикшерү идарәсенең шәхси состав белән эшләү бүлеге башлыгы, юстиция полковнигы **Платонов** Андрей Валерьевичка, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать тәртибен саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне оештыру идарәсенең зур һәм массакүләм спорт чараларының куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлеге хезмәтләр һәм бүлекчәләр эшчәнлеген, дәүләт хакимияте һәм идарә органнары белән хезмәттәшлекне координацияләү бүлекчәсенең махсус йөкләмәләр буенча инспекторы, полиция майоры **Хәбибуллин** Линар Фәрид улына, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм һөнәри эшчәнлектәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы прокуратурасының гомуми һәм махсус эш башкару бүлеге өлкән белгече **Әхмәтова** Наилә Равил кызына; Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының документлар әйләнеше һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы **Примак** Марина Александровнага; күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының үзәкләштерелгән бухгалтериясе җитәкчесе – бүлек башлыгы **Гатауллина** Альбина Дамир кызына; Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре территориаль бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары **Герасимова** Сәрия Дмитриевнага; Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының финанслар белән тәэмин итү үзәге үзәкләштерелгән бухгалтериясе баш бухгалтеры урынбасары **Исмәгыйлева** Гүзәл Рәхмәтулла кызына; күпьеллык намуслы хезмәте һәм республика халкын эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга өлеш кертүе өчен «Кайбыч районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры **Камалиева** Эльвира Рафис кызына; күпьеллык намуслы хезмәте һәм республикада гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу системасын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы **Козырева** Гөлия Фәннур кызына; гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга өлеш кертүе һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Россия юристлар ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Миньязова** Гөлназ Рияз кызына; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм җирле үзидарәне үстерүгә өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгы **Төхвәтуллина** Гөлшат Мөдәррис кызына; дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Документлар белән тәэмин итү идарәсенең Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының норматив-хокукый документлары текстларын тәрҗемә итү һәм тәңгәлләштерү бүлеге өлкән белгече **Хафизова** Илсөя Фәттах кызына **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Тирестә үскән гөлчәчәк,

ЯКИ АЗЧЫЛЫК ХАКЫН КЕМ ХАКЛАР?

«Төркиядә үткән Президент сайлауларында күпчелек (52,18 процент) Рәҗип Әрдоганны яклап тавыш бирү аркасында ул постын саклап калды». «Үз округында күпчелек тавыш җыеп, Фәлән Фәләнов төбәк парламентына депутат булып сайланды». «Күпчелек» сүзе булган, аның өстенлеген раслаган моның ише яңалыклар еш яңгырый. Һәм азчылыкның күпчелек фикеренә буйсынуы безгә һәрчак дөрес һәм гадел тоела. Күпчелек шулай һәрдаим хаклы, ә азчылык хаксызмы соң? Күпчелек ялгышкан чаклар буламы? Була, әле ничек кенә!

«Христосны тәрегә кадакларга!» дигән хөкемне күпчелек хәл итмәгәнме? Гитлер властька килгәндә күпчелек тавыш җыймаганмы? Чиркәү суды – инквизиция шул ук Джордано Бруноны утта яндыруны күпчелек тавыш аша башкармаганмы? Әллә сайлаулар аша үтеп, хакимияткә килгән бөтен илбашлары да үз халкын бәхеттә, рәхәт тормышта яшәтәме? Әле бит күпчелекнең дә төрлесе була: Төркиядәге Президент сайлауларындагы кебек, сан ягыннан азчылыктан азга калышканы яисә, киресенчә, өлкән туган «подавляющее большинство» дип атаганы бар. Үтә дә дөрескә дәгъва кылган соңгы төшенчәне татарчага «басымчаклаучы күпчелек» дип тәрҗемә итәсе түгел микән?

Нәкъ шул җәһәттән мәшһүр «шестидесятник», «җепшеклек» чорында стадионнар җыйган шагыйрь Евгений Евтушенконың фәкыйрегез күптәннән исендә йөрткән, нәкъ менә шул «басымчак» күпчелеккә кагылган шигыре бар. Шуны оригиналда китерәсем бик килә. «Подавляющее большинство, сколько гениев ты раздавило! / Удивляющее меньшинство, сколько раз тебя брали на вилы! / Подавляющее большинство, пахнешь ты как навозная роза, / И всегда подавляешь того, кто высовывается из навоза». Менә шулай. Шагыйрь язганнарда хакыйкать аз дип, кем генә әйтә алыр икән?

Азчылыкны күпчелек мәнфәгатьләренә буйсындыру – демократия принципларының берсе. Әйе, шул ук Черчилль әйткәнчә: «Демократия шәп нәрсә түгел». Халыкның билгеле бер өлешенең теләк, омтылышларын бар дип тә белмәгән идарә ысулы ничек яхшы була алсын инде?! Тик атаклы сәясәтче, шул сүзләргә ялгап, башканы да әйткән: «Әмма кешелек аннан яхшыны әлегәчә уйлап таба алмаган». Демократия шартларында, азчылык күпчелек ихтыярын кабул итмәгәндә анархия, хаос башланырга мөмкин. Демократия байрагы күтәрдеңме, күпчелекне баш та, түш тә итми хәл юк. Әлбәттә, күп илләр демократиясез дә яши. Андый очракта күпчелек тә, азчылык та (андый бүленеш күзәтелгән тәкъдирдә) дәүләт структураларына, хакимият әйткәнгә буйсынырга мәҗбүр. Тик андый тарафларда җәмгыять тар даирә акылы белән яши – субъективлык кайчакта чиктән аша. Субъективлык арту ул – гаделсезлек арту дигән сүз. Элитаның үз мәнфәгатьләре, үз дөреслеге булганда, алар гади халык мәнфәгатьләренә туры килмәгәндә, башкача була да алмыйдыр. Гавам дәүләт кушканча гына уйларга, яшәргә өйрәтелгәндә, башка төрле уйлаучы, гадәттә, аз була, булганнарына диссидент тамгасы тагыла.

Демократиянең алда телгә алынган кимчелеге – күпчелек диктатурасы, гадәттә күп партиялелек белән, сүз ирекe белән компенсацияләнә, дисәк, дөрес булыр. Азчылык мәнфәгатьләрен яклаучы партия парламентта азчылыкны тәшкил итсә дә, гадәттә, ул үз сүзен әйтә килә. Законнар кабул иткәндә, ике якны да канәгатьләндергән килешү – компромисс эзләнә. Компромисс парламентта 3–4 партия торып, алар властька лояль булмаган очракта да табыла. Мондый күренеш – беренче чиратта, цивилизациялелек, өлгергәнлек күрсәткече.

Күпчелекне ачыклау ул – сайлаулар. Парламент, Президент сайлау – дөнья илләренең барысына да хас күренеш. Әмма бу хәл бар тарафларда да күпчелек фикере өстен чыга, азчылык тавышы «глас вопиющего в пустыне» булып калмый дигән сүз түгел. Алдау-йолдау, фальсификацияләрдән күп илләрдә котыла алмыйлар гына түгел, теләмиләр дә. Тавыш бирү дигәндә, тагын берничә нечкәлек бар. Беренчедән, ул – гомумән дә пассив гамәл. Барсаң ярый, бармасаң да сүз әйтүче юк. Сайлауларга беркайчан да йөрмәүче, «бездән – гади кешедән бер нәрсә дә тормый» дигән фәлсәфәгә бирешкәннәр дә җитәрлек. Битарафлыкка кайтып калган мондый позиция – иң начары. Барган, тавыш биргән очракта да халыкның шактый өлеше ул эшне артыгын уйлап, анализлап, баш ватып эшләми.

Ә гомумән алганда, иленә, җиренә карамастан, барлык кешегә дә сайлау хокукы бирүне бик үк дөрес сәясәт димәс идем. Ил язмышларын җаваплы, белемле, актив гражданлык позициясе булганнар гына хәл итәргә хокуклы кебек. Ләкин кемнедер сайлау хокукыннан мәхрүм итү җәмгыятьтәге кануннарга каршы килә. Җаваплылыкны, актив гражданлык позициясе барын яисә юклыгын кем, ничек, ни рәвешле билгели, шунысы да бар бит әле. Шул ук яшьләр сәясәт белән аз кызыксына. Шул сәбәпле, мәсәлән, 25 яисә 30 яше тулып узганнарны гына сайлауда катнаштыруда мантыйк бар да кебек. Тик моны «кеше хокукларын бозу» дип атаячаклар һәм, ихтимал, хаклы да булачаклар. Бәлки кайчан да, кайда да булса сайлау хокукы алу өчен тест үтү кертелер дә. Әмма андый чикләүне кабул итмәүчеләр күп булачак. Икенче яктан алганда, сәяси-иҗтимагый тормышка бөтенләй битараф яисә аны аңламаган, аңларга да теләмәгән кешенең, участокка барып, тавыш биреп йөрүендә мантыйк гел дә юк бит. Дәүләттәге тәртипләрне, аның иртәгесен аңлы һәм актив гражданнар хәл иткәндә генә тормыш яхшыра, гаделлек, объективлык арта ала. Тик андыйлар, ни кызганыч, бүген тагын да шул азчылыкта әле.

ТАТАР ФӘНЕ ГОРУРЛЫГЫ

ОЛПАТ ГАЛИМ МИРФАТЫЙХ ЗӘКИЕВ АРАБЫЗДАН МӘҢГЕЛЕККӘ КИТЕП БАРДЫ

Фән дөньясы филология фәннәре докторы, Россия Лингвистика фәннәре академиясе академигы, Россия һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Мирфатыйх Зәкиев белән мәңгелеккә хушлашты. 95 яшенә кадәр Диссертация советы әгъзасы буларак, яшь белгечләргә фәнни хезмәтләр яклаткан әле ул! Аның шушы яшькә кадәр йога белән шөгыльләнүен дә беләбез.

Мәрхүмне Самосырово мөселман зиратында җирләделәр. Хушлашу мәрасимендә Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләре телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов та катнашты. «Мирфатыйх ага кебек абруйлы шәхесне югалту – татар дөньясы өчен зур кайгы», – дип белдерде ул. Аның балачагын да искә алды. Кечкенә Мирфатыйх – сугыш чоры баласы, алты яшеннән әтисез калган. Гаиләдә иң олы бала. Әне-сеңелләренең тамагы тук булсын дип, көтү көтеп, ат карап, тимерче булып эшләп, тормышта үз урынын таба алган.

– Мирфатыйх Зәкиев Югары Совет Рәисе вазыйфасын үтәде. Ул чорда әлеге вазыйфаны искиткеч дәрәҗәле шәхесләргә генә ышанып тапшырганнар. Менә нинди кеше ул безнең! – диде Марат Әхмәтов.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин Мирфатыйх Зәки улының Татарстанның Фәннәр академиясен төзүдә төп оештыручыларның берсе булуын әйтте. Аның кырык елга якын гомере академик фән белән бәйле.

– Мирфатыйх Зәкиев 1986 елда институтка директор вазыйфасына килде. Җәмгыятьтә зур үзгәрешләр башланган, милли кыйблабызны эзли башлаган вакыт. Ул фәнне яңа баскычка күтәрә алды, – диде.

Олпат галим турында Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты Дания Заһидуллинаның да фикерен сораштык.

– XX гасырның татар тел гыйлеме фәнендә Мирфатыйх Зәки улы әлеге фәнне төрки дөньяга чыгарган зур галим булды. Ул татар теленең үзенчәлекләрен төрки халыклар тарихы белән кушып өйрәнү омтылышын ясады. Шуның белән бергә татар телен генә түгел, башка халыкларның телләрен дә шушы системага урнаштыру турында уйланды. Шәхесне, аның хезмәтләрен башка төрки халыклар, беренче чиратта, казах, кыргыз, башкорт, төрекмәннәр аерым хөрмәт белән искә ала. Татар дөньясында шундый аксакалның булуы – татар фәненең горурлыгы, – диде Дания Заһидуллина.

Галимә әйтүенчә, Мирфатыйх Зәкиев шушы яшькә кадәр Диссертацияләр яклау советы әгъзасы булган. Яшь доктор, кандидатларны диссертация яклатуга үз өлешен кертеп, хәер-фатихасын биргән. Сүз уңаеннан, Мирфатыйх Зәкиев җитәкчелегендә 60ка якын фән кандидаты һәм 18 фән докторы әзерләнгән. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, Татарстан алдындагы казанышлар өчен орденнары, күпсанлы медальләр, мактаулы исемнәр белән бүләкләнгән ул.

Моннан берничә ел элек без дә Мирфатыйх абыйның өендә кунакта булган идек. Аның 50 елдан артык йога белән шөгыльләнүе бик кызык тоелган иде. Ул чакта: «Мине йога яшәтә. Кәефне күтәрә, сәламәтлекне яхшырта ул. Озын гомерле буласың килсә, күнегүләр ясауны туктатмыйсың. Моның өчен иртән 40–45 минут вакытымны бүләм. Көн саен җәяү йөрим», – дигән иде.

Мирфатыйх абый үзе туып-үскән Ютазы районының Зәйпе авылын (хәзерге Баулы районы) искә төшермичә калмады ул чакта. «Бүген авылда йортлар калмады инде. Шулай да зираты бар. Елга бер мәртәбә якыннарым рухына дога кылырга кайтам. Туган якларны әйләнеп килү – үзе бер бәхет», – дигән иде мәрхүм галим.

Бүген инде үзе бакыйлыкка күчте. Үзе китте, фәндә тирән эзе калды. Рухыгыз шат булсын, Мирфатыйх ага! Белем нуры караңгы гүрегезгә яктылык өстәсен.

Сәрия МИФТАХОВА

ЗӘКИЕВ МИРФАТЫЙХ ЗӘКИ УЛЫ

(14.08.1928 – 18.08.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге зур югалту кичерә.

2023 елның 18 августында 96 нчы яшендә танылган галим, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт премиясе лауреаты Зәкиев Мирфатыйх Зәки улы вафат булды.

М.З. Зәкиев 1928 елның 14 августында ТАССРның Ютазы (хәзерге Баулы) районы Зәйпе авылында туган. 1951 елда В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген бик яхшы билгеләргә тәмамлаган.

М.З. Зәкиев үзенең хезмәт эшчәнлеген мәктәп елларында башлап җибәрә, колхозда көтүче, ат караучы, тимерче булып эшли. Югары белем алганнан һәм аспирантура тәмамлаганнан соң, 1954 елда Казан дәүләт университетының өлкән укытучысы була, 1960 елда татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире итеп билгеләнә. 1965 елда Казан дәүләт педагогика институтының фәнни эшләр буенча проректоры вазыйфасына күчә.

1967 елдан 1986 елга кадәр Казан дәүләт педагогика институтын һәм татар тел белеме кафедрасын җитәкли. 1986 елда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты (ул 1993 елдан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе составына керә) директоры итеп билгеләнә. 2000 елдан – тел белеме кафедрасы мөдире, 2007 елдан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты лексикология һәм диалектология бүлеге мөдире булып эшли.

М.З. Зәкиев бөтен гомерен фәнгә, югары белемгә багышлады. Ул педагогик кадрлар әзерләүнең республика системасын булдыруга, шулай ук Татарстанның фән-мәгариф өлкәсен үстерүгә зур өлеш кертте.

Профессор, тарихчы һәм тел галиме М.З. Зәкиев – 1 меңнән артык фәнни эш, шул исәптән 100дән артык монография, татар теле һәм төрки тел белеме, төрки халыкларның этник тарихы, икетеллелек һәм күптеллелек буенча дәреслекләр һәм укыту әсбаплары авторы. Аның «Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис», «Татар теленең синтаксик төзелеше» монографияләре татар теле эволюциясе мәсьәләләрендә төп фундаменталь тикшеренүләр булып тора. Республиканың мәгариф учреждениеләрендә татар телен укыту методикасы хәзерге вакытка кадәр академикның хезмәтләренә нигезләнеп төзелә.

Ул актив иҗтимагый эшчәнлек алып барды, ТАССРның унынчы һәм унберенче чакырылыш Югары Советы депутаты итеп сайланды, 1980 елдан 1990 елга кадәр ТАССР Югары Советы Рәисе булды. Республика халыклары телләре турындагы закон проектын әзерләү буенча Татарстан Республикасы Югары Советы комиссиясен җитәкләде.

М.З. Зәкиев Россия Лингвистика фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы, Болгар белеме, инновация һәм мәдәният халыкара академиясе академигы, Россия тюркологлар комитеты әгъзасы, Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия милли университетының (Казахстан) халыкара тюркология үзәге президиумының мактаулы әгъзасы булып торды.

М.З. Зәкиевнең күпьеллык нәтиҗәле фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, аның татар халкы мәдәниятен һәм традицияләрен үстерүдәге һәм саклаудагы казанышлары югары бүләкләр белән билгеләп үтелде, алар исәбендә Хезмәт Кызыл Байрагы, «Халыклар дуслыгы», «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлар өчен», «Дуслык» орденнары, «Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә», «1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында данлы хезмәт өчен», «1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең утыз еллыгы», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел» медальләре бар.

М.З. Зәкиевнең тормыш юлы зур хөрмәткә лаек. Җәмгыять алдында үзен бурычлы итеп тоюы, җаваплылыгы, оптимистлыгы һәм кешеләргә карата сизгер мөнәсәбәте белән ул абруй казанды, коллегаларының һәм республика җәмәгатьчелегенең тирән ихтирамына лаек булды. Ул һәрвакыт яраткан эшенә бирелгәнлеге һәм халыкка чын күңелдән хезмәт итүе белән аерылып тора иде.

Уникаль язмыш кешесе, талантлы җитәкче һәм профессионал Зәкиев Мирфатыйх Зәки улы турында якты истәлек безнең йөрәкләрдә гомерлеккә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ,
Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН,
Ә.Ә. СӘФӘРОВ, М.Г. ӘХМӘТОВ,
И.Г. ҺАДИУЛЛИН, Р.Н. МИҢНЕХАНОВ,
Л.Р. САФИН, И.Р. МЕТШИН,
И.И. ГОЗӘЕРОВ

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, галим Мирфатыйх Зәкиевнең вафаты уңаеннан, Татарстан Фәннәр Академиясе президенты Рифкать Миңнехановка кайгы уртаклашу телеграммасы юллады.

«Татар халкының күренекле улы, зур галим, талантлы һәм кабатланмас шәхес Мирфатыйх Зәки улы Зәкиевнең вафаты уңаеннан олы кайгы уртаклашам. Мирфатыйх Зәки улының татар тел белеме һәм тюркология фәне үсешенә, республиканың югары мәктәбе мөмкинлекләрен арттыруга, сайлаган хезмәт юлына чиксез тугрылык һәм туктаусыз иҗади эзләнүләр рухында яшь галимнәр тәрбияләү эшенә керткән өлеше бәяләп бетергесез, – диелә телеграммада. – Әлеге зыялы, нык ихтыярлы, максатчан һәм эш сөючән олуг затның тормыш юлы һәркем өчен үзенең яраткан һөнәренә, газиз халкына, туган иленә хезмәт итүгә багышлауның күркәм үрнәге булып тора. Мирфатыйх Зәки улы олы ихтирамга лаек, игелекле, матур озын гомер кичерде һәм киләчәк буыннарга тиңдәшсез фәнни мирас һәм үзе турында бары тик изге хатирәләр генә калдырды.

Чын күңелдән барлык Татарстан халкының, Мирфатыйх Зәки улының туганнарының һәм якыннарының олы хәсрәтен уртаклашам. Рөстәм Мирфатыйх улына һәм Илдар Мирфатыйх улына, әтиләре вафаты сәбәпле тирән кайгыларын уртаклашып, ихлас йөрәктән күркәм сабырлыклар телим.

Мәрхүмнең авыр туфрагы җиңел, урыны оҗмах түрендә булсын».

Танылган галим һәм җәмәгать эшлеклесенең вафат булуы сәбәпле, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин парламент депутатлары исеменнән һәм шәхсән үз исеменнән Мирфатыйх Зәки улының гаиләсе, хезмәттәшләре һәм шәкертләренең авыр кайгысын уртаклашты.

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, филология фәннәре докторы, профессор, Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, татар халкының телен, мәдәниятен, традицияләрен, милли үзаңын саклауга һәм үстерүгә зур өлеш керткән талантлы галим Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев хөрмәткә лаек тормыш юлы узды, – диелә ТР Фәннәр академиясе җитәкчелегенә җибәрелгән телеграммада. – Югары эшлекле һәм шәхси сыйфатлары, нәтиҗәле фәнни-тикшеренү, педагогик, ТАССР Югары Советы Рәисе вазыйфасында иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге Мирфатыйх Зәки улына һөнәри мохиттә зур абруй һәм киң җәмәгатьчелекнең ихтирамын китерде. Аның Ватан алдындагы казанышлары бик күп бүләкләр һәм мактаулы исемнәр белән билгеләп үтелде».

Фәрит Мөхәммәтшин Мирфатыйх Зәки улының туганнарына һәм якыннарына кайгы уртаклашу һәм хуплау сүзләрен җиткерде. «Бу зирәк кеше, чын ватанпәрвәр һәм татар халкының данлыклы улы турында якты истәлек аны белгән, аның белән бергә эшләү бәхетенә ирешкән һәркемнең хәтерендә гомерлеккә калыр», – диелә телеграммада.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы коллективы, республиканың барлык педагоглары һәм фән эшлеклеләре җәмәгатьчелеге, Казан педагогика институтының элеккеге ректоры, танылган галим, филология фәннәре докторы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Мирфатыйх Зәки улы Зәкиевнең арабыздан китү кайгысын кичерә.

Мирфатыйх Зәки улының педагогик кадрлар әзерләүгә, татар әдәби теле һәм татар халкы тарихы эволюциясе проблемаларын тикшерүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Олпат галим хезмәттәшләре арасында да зур абруй казанды, бөтен педагогик җәмәгатьчелекнең дә тирән ихтирамын яулады. Мирфатыйх Зәки улы вафаты сәбәпле, аның гаиләсе, шәкертләре, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклашабыз.

Аның турында якты истәлек безнең йөрәкләрдә мәңге сакланачак.

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, КамАЗны оештырган Лев Борисович Васильев вафаты уңаеннан, мәрхүмнең хатынына кайгы уртаклашу телеграммасы юллады.

«Хөрмәтле Инна Вениаминовна!

Татарстанлылар исеменнән һәм шәхсән үземнән, ирегез Лев Борисович Васильев вафаты уңаеннан, тирән кайгыгызны уртаклашуыбызны кабул итегез.

Аның исеменә Кама автогиганты һәм Чаллы шәһәре төзелеше, гомумән, илебез автомобиль сәнәгатенең һәм машина төзелешенең нәтиҗәле үсеше бәйләнгән атаклы җитәкче дөньядан китте, – диелә телеграммада. – Масштаблы, кабатланмас шәхес буларак, Лев Борисович исән вакытында ук чын легендага әверелгән иде. Аның искиткеч хезмәт сөючәнлеген, максатчанлыгын, куәтле иҗади рухын, үз тирәсендәге кешеләрне бергә туплый һәм актив эшләүгә рухландыра белүен камазлылар, һөнәр һәм тормыш юлларында бу уникаль кеше белән очрашу бәхетенә ия булганнар барысы да бүген чиксез ихтирам һәм рәхмәт сүзләре белән искә ала. Лев Борисовичның озын, вакыйгаларга бай һәм эчтәлекле, чын-чынлап матур тормышы туган иленә һәм халкына ихлас күңелдән хезмәт итүнең, һөнәренә тугрылыкның һәм кешеләрне бик нык яратуның бәяләп бетергесез үрнәге булып тора. Татарстанлыларның хәтерендә Лев Борисович Васильев нәкъ шундый: көчле, талантлы җитәкче, хезмәтенә бирелгән, якты һәм юмарт күңелле кеше булып калачак.

Сезнең белән бергә кайгырабыз, Сезнең һәм Лев Борисовичның барлык якыннары белән бу кире кайтарып булмаслык зур югалту ачысын бүлешәбез. Сез йөрәгегезгә иң якын, иң кадерле кешеләрегезнең берсен, гомер юлыннан җитәкләшеп атлаган, бөтен шатлык һәм борчуларыгыз уртак булган затны югалттыгыз. Бирешмәгез, бу авыр, хәсрәтле көннәрдә көчле рухлы булуыгызны телибез, туганнарыгыз һәрчак янығызда булсын».

ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН ТӨЗҮЧЕСЕ МАРАТ РИЗВАНОВ:

«ЭШЛИ БЕЛМӘГӘН КЕШЕГӘ УЧ ТУТЫРЫП АКЧА БИРЕП БУЛМЫЙ»

Эш кешесе

Төзүчеләр көне уңаеннан, аңлашыла ки, Татарстан Республикасының Төзүчеләр берлегенә сугылып чыгуыбыз – гадәти күренеш. «Хәл-әхвәлләре ничек?», «Бәйрәмне ничек каршылыйлар?» дигән сорауларга җавап табу иде ниятебез. Ә монда икеләтә бәйрәм булып чыкты. Берлекнең башкарма комитеты директоры Марат РИЗВАНОВның юбилее – шушы көннәрдә 75 яшь тула. Форсаттан файдаланып, илле генә әңгәмә корып алдык.

:: Марат Вәгыйзович, төзүчеләрнең иксез-чиксез эшләре һәм кадрлар турында сүз алып барыр алдыннан, һөнәрне сайлау турында белешергә иде. Мәктәп эскәмиясеннән башлап шушы көнгәчә төзүче һөнәренә хыянәт итмәгән кеше дип сөйлиләр. Дөрес сүзме бу?

– Безнең заман балаларының һәрберсе, тәпи йөри башлауга, үзенчә төзүче булган инде ул: каккан, суккан, төзәткән. Ә минем, чыннан да, хыялым иде ул – төзүче булу. Сәбәбе дә бар. Азнакай районының Чатыр таудан ерак түгел Сухояш авылында туганмын мин. Әтием әниемне өч бала белән ташлап киткән. Аны хәтерләмим дә. Ул вакытта бер яшьлек кенә булганмын. Күрше авылда гына яшәсә дә, әти безнең белән аралашуны кирәк дип тапмаган. Педучилище тәмамлаган әнием мәктәптә укытты. Мәктәп дигәннәре – кыш көннәрендә өч тапкыр ягыла торган борынгы агач бина. Шуның янындагы бер йортта яшәдек без. Йорт дисәң, хәтере калыр, төзелеп тә бетмәгән иде әле ул. Чоланы да юк, кыш көннәрендә бер бүлмә генә җылытыла. Әни төнлә торып мичкә яга, әз генә җылы төшкән сыман була. Әмма мичкә артны терәп утырырга вакыт юк, шундый ук салкын мәктәпкә кереп китәргә кирәк. Шулвакытта йөрәгемә үткәндер инде: мин яңа йортлар, яңа мәктәпләр төзү турында хыялландым. Әйе, мәктәп елларында ук хыялымны тормышка ашыра да башладым. Югары сыйныфларда Азнакайда укыдым. Шунда производство дәресләрендә малайларны ташчы һөнәренә өйрәттеләр. Без аттестат белән бергә һөнәр дә алып чыктык, азрак акча эшләргә дә өлгердек.

:: Казан төзелеш институтында укыганда да сайлаган кыйблагыздан бер адым да читкә китмәгәнсез...

– 1966 елда институтка укырга керүем студент төзелеш отрядлары оештырылу чорына туры килде. Икенче курстан ук Арча районында авыл хуҗалыгы корылмалары сафка бастырдык. Өченче курстан соң мин инде мастер идем: Лениногорск районында торак йортлар, хастаханә, мәктәпләр төзедек. Дүртенче курстан соң зона студентлар отрядының баш инженеры итеп тәгаенләделәр. Безнең отряд Кама арьягында Чистайдан алып Мөслимгә кадәр дистәләрчә төзелештә эшләде. Мин көн саен аларның хәлләрен белешеп, эшләрен барлап, ярдәм итеп, материаллар һәм эш инструментлары белән тәэмин итеп, ашау-эчуләрен кайгыртып, килеп туган проблемаларны хәл итеп йөрдем. Кыскасы, тормыш кайнап торды һәм бу миңа бик ошый иде. Институт тәмамлаганда мин инде шактый гына тәҗрибә тупларга өлгердем.

:: Мондый тәҗрибәне нинди эшләрдә кулланырга мөмкинлек булды?

– Диплом яклаганнан соң, яхшы эш урыны эзләргә кирәк иде. Чөнки мин инде гаилә корырга да өлгердем. Балабыз да бар. Яшәргә урын да кирәк. Башта берәр авыл төзелешенә китәрмен дә рәхәтләнеп яшәрбез, шуннан кулайрагы булмас дип уйлаган идем. Әмма Кама автозаводы төзелеше үзенә тартты. Житмәсә, кадрлар сайлау өчен төзелеш начальнигы урынбасары Хәниф Шәйхетдинов үзе килде. Хәтта фатир бирәбез дип тә вәгъдә итте. Профессиональ төзүчеләр җитешми икән. Бер елдан «Автозаводстрой»да мастер булып эшли башладым. Бер айдан фатир ачкычы тапшырдылар.

Бер елдан мине ВЛКСМ шәһәр комитетына чакырып алдылар да Бөтенсоюз КамАЗ студентлар төзелеш отрядының баш инженеры итеп билгеләргә карар кылдылар. Соңрак отрядның командиры булырга тәкъдим иттеләр. Тагын ике ел Бөтенсоюз комсомол төзелеше штабын җитәкләдем. Әйтергә кирәк, ул чорда комсомол-яшьләр отрядларына иң мөһим объектларны тапшырдылар, һәм без аларны тиз арада, сыйфатлы итеп тапшырырга тиеш идек. 1978 елда гына комсомол һәм партия эшләреннән арынып, ниһаять, җитештерү өлкәсенә кучә алдым: СМУ-5 начальнигы булып эшли башладым. Әмма бу уттан чыгып, суга кергән кебегрәк булды. Безгә Чулман елгасында суднолар йөрер өчен юл ачарга кирәк иде. Вакытында өлгерү өчен бер мең ярым кеше дүрт сменага бүленеп, алтышар сәгать тәүлек буена эшләдек. Аннан да артык түзәргә мөмкин түгел иде, чөнки ул елны кыш бик салкын килде. Мин үзем ярты еллап өйгә дә кайта алмадым, гидростанциядәге вагонда яшәдем.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Димәк, КамАЗ һәм Яр Чаллы төзелеше сезнең өчен зур хезмәт мәктәбе булган дип уйларга нигез бар?

– Әлбәттә. Аннан ничектер шулай туры килде. Мине СССР Газпромының иң зур берләшмәләреннән берсе «Средневолжскгаз»га директор урынбасары итеп билгеләделәр. Бу Уренгой – Помары – Ужгород, Уренгой – Үзәк линияләрендә газ торбалары үткәрү чоры иде. Без компрессор станцияләре төзедек, республика авылларын газлаштыру белән шөгыльләндек. Әйтергә кирәк, бу минем өчен бөтенләй яңа тармак булды. Әмма остазларым ярдәмендә эшнең серенә бик тиз төшендем.

1984 елда Казанда «Востокстройтрансгаз» тресты оештырылды. Анда баш инженер булып эшләдем. Ике елдан исә «Татагропромстрой» берләшмәсенә генераль директор урынбасары – баш инженер булып күчтем. Авыл кешесе булгач, монысы нәкъ минем өчен тәгаенләнгән эш кебек иде. Без заводлар, базалар, проект институтлары, урман хуҗалыклары өчен корылмалар төзедек. Авыл кешеләренең гозерен дә, теләк-хыялларын да аңлап эш иттек. 25 ел эчендә йөзләрчә социаль объектлар, төзелеш материаллары җитештерү буенча заводлар, фермалар, торак йортлар төзелде... Ул чакта Татарстанның аграр сәнәгате аякка бастырылды. Балачак хыялым да тормышка ашты: мәктәпләр, балалар бакчалары, бик матур торак йортлар сафка басты.

:: Төзүчеләр берлеген оештыру идеясе ничек барлыкка килде?

– Бу оешма 1999 елда барлыкка килде. Аның башында Татарстанның атказанган төзүчесе Рим Халитов торды. Без аның эшен дәвам иттек. Хәтерлисездер: туксанынчы елларда, ничектер, барысы да бик тиз җимерелде бит. Алга таба төзелеш эшләрен алып бару өчен исән калганнарын белән яңа аякка басарга азапланганнарын туплярга, аларның мәнфәгатьләрен якларга, сакларга кирәк иде. Ягъни Министрлар Кабинеты белән төзелеш оешмалары арасында күпер төзергә кирәк булды. Берлек шул нияттән төзелде. Эшебез күпкырлы. Шул исәптән кадрлар туплау белән дә шөгыльләнәбез. Моның өчен Төзелеш министрлыгы һәм Мәгариф министрлыгы белән тыгыз элемтәдә эшләдек. Төзелеш көллиятләре, техникумнарның хәлләрен дә күзәтеп торабыз. Бүген Татарстанда төзүчеләр әзерли торган 14 көллият бар. Тик менә укырга теләүчеләр күп, эшләргә теләүчеләре генә аз.

> Укуны тәмамлаучыларның күп дигәндә 20 проценты гына төзелешкә килә. Элеккеге кебек юллама системасы кертелмәсә, бу югалтуларга чик куеп булмас, мөгаен. Алар дәүләт хисабына укыйлар бит, димәк, моның өчен түләргә дә тиешләр. Бу хакта Мәгариф министрлыгына фикерләребезне җиткердек.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ХӘТӘЛИ БӘРӘҢГЕСЕ

Безнең бәйрәмнәр

Җәйге чиллә тә юлга чыгасы килмәгән иде үзе, әмма хезмәттәшем Зөлфия Хәлиуллинаның: «Синең Бәрәңге бәйрәмен күргәнең юктыр әле, Әтнә якларына барып кайтмыйсыңмы?» – дигәе миңа җитә калды. Без бит инде – һәрнәрсә белән кызыксына торган халык, эшебез шул, ә Бәрәңге бәйрәме турында ишеткәнем дә юк иде. Бер уйлаганда, татар матур йолалары, бәйрәмнәре күп булу белән горурлана ала.

Алар, нигездә, авыл җирләрендә саклана. Бүген күпләр: «Авыллар бетә!» – дип шәрран ярганда, янадан-яңа бәйрәмнәр уздырыла башлавы куандыра. Әтнә – саф татар районы. Дөрес, элегрәк әтнәләләр ярым шаяртып, ярым җитди дигәндәй: «Бездә бер яһүд, бер әрмән гаиләсе яши. Алар монда шабашкага килгән булганнар һәм тормышыбызга кызыгып төпләнеп калганнар», – дип сөйлиләр иде. Хәзер андый сүзләр ишетелми, димәк, бүгенге көндә Әтнә тарлардан гына торадыр дигән шик бар. Һәрхәлдә, бу якларга килсәм, татар теле колакны, күңелне иркәли, мондый мохиттә йола-бәйрәмнәрнең яшәве, алай гына да түгел, яңадан барлыкка килү табигый.

Бәрәңге бәйрәме Әтнәнең Ары авылында уза. Клуб каршында бәрәңгедән төрле ризыклар пешереп, уеннар оештырылып, җырлап-биеп башланган бәйрәм хәзер авыл Сабантуйларына биргесез. Халык күп, мәйдан тирәли кибетләр эшләп тора, сәүдәгәрләр хәтта Чувашиянең Шыгырдан авылыннан да килгәннәр, шашлык, төрле тәм-том сатылар. Арча, Биектау, Яшел Үзән фольклор ансамбльләре эмь өстенә эмь өстәделәр.

Язмамны «Хәтәли бәрәңгесе» дип атауның кечкенә генә бер сере бар. Ул серне Ары мәдәният йорты директоры Раилә Кадыймова ачты. Борын-борын заманда дигәндәй авылда Мөхәммәтгали исемле бер бабай яшәгән. Бәрәңгене әрчеп, урталай ярып, майлы табада кыздыручы бердәнбер кеше булган ул авылда; күрәсең, бәрәңгене майлы табада хәлле кеше генә кыздыра алган. Авыл халкы Мөхәммәтгалинең исемен үзенчә «Хәтәли» дип үзгәрткән һәм «Хәтәли бәрәңгесе» дигән сүз инде ничә еллар буе яшәп килә, таба бәрәңгесе бүген бәйрәмнең иң затлы ризыгы санала. Бәйрәм өстәлендә дистәдән артык бәрәңге ризыгы бар иде.

«Ары мәдәният йорты» дигәнем – гади бер авыл клубы инде ул. Ташкүмер, утын ягып җылытыла. «Кочегар» исә – Раиләнең ире Фидаил. Әмма ул мичкә ягучы гына түгел, Раиләнең төп таянычы. Мин аңа: «Уттай кызу урак өстендә бәйрәм оештырышгызны өнәп бетермәүчеләр дә бардыр», – дигән идем, Фидаил: «Игенче иген игә, ә мәдәният хезмәткәре, бәйрәм ясап, җырлап-биеп, аның күңелен күтәрергә тиеш», – дип әйтте дә куйды. Моңа каршы ни дисең инде! Гаҗәеп пар бу Раилә белән Фидаил. «Әтнә таңы» газетасы мөхәррире Гөлнар Мөхәммәтҗанова: «Риман абый, Раилә белән Фидаил, кичен йокларга яткач та, иртәгә нинди бәйрәм үткәрү турында хыялланмыйлар микән дип шикләнәм. Алар кебек фанатикларны моңарчы күргәнем дә, ишеткәнем дә юк», – дигән иде. Раилә белән Фидаил, һәр елны Кар кызы һәм Кыш бабай булып киенеп, редакция хезмәткәрләрен, тагын кайбер оешмаларда эшләүчеләрне Яңа ел белән котлап йөрергә дә вакыт табалар икән. Арыдан Әтнәгә хәтсез ерак ара бит әле! Кайбер авылларда мәдәният, клублар эше аларны ачып-ябуга гына кайтып кала. Мондый эш «алым»ын авылның картаюы, мәдәният йортларына йөрүче калмау белән аңлаталар. Андыйлар Арыга килеп китсен иде. Раилә алар: «Эшне аны яратып та эшләп була», – дияр иде, Фидаил исә: «Ходай миңа Раиләне, Раиләгә мине биргән, без бер-беребезне тулыландырып, бербөтен булып яшибез», – дип өстәр иде.

Халык бәйрәмнәре туу гадәттә берәр вакыйга, шәхес, йолага бәйле була. Бәрәңге бәйрәме дә, аның август башында үткәрелүе да авыл халкының яңа бәрәңгедән авыз итеп каравына бәйле икән. Моны Раилә сөйләде. Аның әби-бабасы: «Бүген икенче август, яңа бәрәңге ашап карыйбыз», – дип әйтә торган булганнар. Ул көнне күрше-күләнне кунакка дәшеп, яңа бәрәңгедән авыз иттерү өстенә, сөйләшеп-җырлашып та утырганнар.

> **Бәйрәмнәрнең асылын нечкәләп карасаң, аларда – халкыбызның яшәү рәвеше, төрле заманнарда җырлаган җырлары, биегән биюләре, зирәклектә, җитезлектә сынаша торган уеннары.**

Мине Кошлау авылы мәдәният йорты директоры Зөлфия Шакирова сөйләгәннәр дә шактый уйландырды. Бу авылда «Җиз самавыр бәйрәме» уза икән. Зөлфия әйтүенчә, беркөнне нииндидер чарага әзерләнгәндә, өлкән яшьтәге бер апа элек авыл кешеләренең һәр язны Маһитап чишмәсе янында самавыр уюларын искә төшергән. Авыл хатыннары җиз самавырларын ком белән ышкып ялт иттерә торган булганнар, шунда ук җиз самавырдан җиләкле мәтрүшкәле чәй эчеп, җырлашып, серләшеп утырганнар. «Кара әле, нигә китаптан йолалар эзләп утырган булабыз, әзере бар икән бит, дидек тә «Җиз самавыр бәйрәме» үткәрә башладык», – диде Зөлфия. Авылда хәбәр тиз тарала бит инде ул, икенче елны ук бәйрәмгә күрше-тирә авыллардан килә башлаганнар, аннан соң үзләре республика районнарының мәдәният бүлеге җитәкчеләрен чакырганнар, нәтиҗәдә бәйрәм республика дәрәҗәсенә күтәрелгән. Быел тугыз районнан килгән фольклор коллективлары үз төбәкләренә хас йола-бәйрәмнәр күрсәткәннәр. Җиз самавырлардан күгәзмә да оештырылган. Әйтүләренчә, араларында йөз яшьлек самавырлар да булган.

Әтнәдән кайтканда, «яшәсен бәйрәмнәр» дигән сүзләр гел тел очымда әйләнде. Бәйрәмнәребез белән бергә телебез дә, мәдәниятебез дә, күркәм йола-гадәтләребез дә, димәк, милләтебез дә яшәр.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Сөклану

Тырышлык әҗере

Мөслим кызы Лиана Исмәгыйлева химия, биология фәннәреннән имтиханнарда 100әр балл туплаган. Ул Казан дәүләт медицина университетының дәвалау эше факультетына укырга кергән. «Әти-әниемнән, туганнарымнан аерылып, еракка китәргә теләмәдем. Татарстанда каласым килде», – ди 18 яшьлек Лиана.

Лиана имтиханнарга ныклап 10 нчы сыйныфны тәмамлагач, җәйге каникулда әзерләнә башлый. «100 баллы репетитор» онлайн мәктәбенә язылып, курслар сатып алган. Анда файдалы яңалыклар күп, өй эшен дә мулдан бирәләр, хаталарны да яхшылап аңлаталар икән. Лиана дәресләрнең берсен дә калдырмаган. Китаплар сатып алып, өстәмә биремнәр дә чишкән. Мәктәптә химия, биология фәннәрен яратып укыган. Укудан кайтып, ашап-эчкәч, көн саен имтиханнарга әзерләнгән. Тик сәгать 11дән соңга калмыйча ятарга тырышкан. Уку гына түгел, йокы да мөһим бит. Шул ук вакытта әдәби китаплар укып, тел байлыгын арттырган. Монысы – яраткан шөгыле. Иртүк торып спорт белән шөгыльләнергә дә җай тапкан. Килачәктә табиб булырга хыялланган Лиана башкаларга да вакытны дөрес бүлеп яшәргә киңәш итә.

– Ике фәннән йөзәр балл туплармын дип көтмәгән идем. Ләкин химия сынавын биреп чыккач, абсолют нәтиҗәгә ирешәчәгемә ышандым. Бу хакта әтиәниемә, укытучыма әйтмәдем. Ә биологиягә мине шаккатырды. Ни өчен дигәндә, 100гә үк өмет итмәгән идем, – ди Лиана. – Имтиханнардан 293 балл җыйдым. Вузда алтын медаль өчен – 6, ГТО значогына ике балл өстәделәр.

Гадәттә, 100 балл җыючыларны вузларга югары стипендия белән җәлеп итәргә тырышалар. Узенчә кызыксындыру чарасы, уку әҗере инде бу. «Республика тарафыннан БДИда 200 балл туплаучыларга бирелгән 25 мең сум акчаны алдым. КДМУда әлнә ни күп акча бирү каралмаган. Шулай да Яңа елга кадәр 20шәр мең сум стипендия бирәбез, дип вәгъдә иттеләр. Акчаны җыеп барам, кирәк вакытта тотачакмын», – ди булачак студент.

Мәктәп хәлләре турында да сораштык. Нииндидер фәнне үзгәртергә кирәк дип уйлаганы булмаган. «Безнең биргән тә рәхмәт», – ди. Ә иң яраткан укытучысы – математика укытучысы Рәмилә Гуссамова. «Рәмилә апа сабыр, мәрхәмәтле, тырыш, укучыларны аңлый һәм тырышлыкны күрә белә. Кирәк вакытта таләпчән һәм шаян телле дә. Дәреснең бер генә минутын да әрәм итми. Химияне өйрәнгәндә математика белеменең файдасы зур булды. Анда да биремнәр чишәбез бит. Мәкалә язганда, берүк укытучымның исемен төшереп калдыра күрмәгез, яме», – дип үтенде ул.

Лиананың бер генә мәртәбә дә «2ле» алганы булмаган. Барлык дәрескә дә әзерләнеп, аңламаганын видеодан өйрәнеп барган мәктәпкә. Шулай булгач, мондый тырыш укучы начар билге ала димени? «2ле» куйсалар да, хурлык дип санамас идем. Ул миңа тагын да тырышып укырга этәргеч бирер иде», – ди Лиана, начар билгегә мөнәсәбәтен белдереп.

Кечкенәдән табиб булырга хыялланган ул. Үрнәк алырлык кешесе дә бар. Иске Карамалы авылында озак еллар акушер-гинеколог булып эшләгән, хәзер лаеклы ялда булган әбисе Гөлүсә ул! «Аның юлын хәзер мин – оныгы дәвам иттерәчәкмен. Яхшы табиб булырга сүз бирәм. Хезмәтемә бармак аша гына карамаячакмын», – ди Лиана Исмәгыйлева.

Сәрия МИФТАХОВА

Кариев театрының «Ал җилкәннәр» спектакленнән күренеш.

ПӘРДӘЛӘР АЧЫЛА

Театр дөньясында

Җәйге ял тәмам, театрлар яңа сезонга әзерләнә. Өлгеррәкләре сезонны ачты да инде. Татар театрлары яңа сезонда ниләр күрсәтәчәк? Нинди премьералар көтелә? Без шуны белештек.

Камал театры

Камаллылар 118 нче сезоннарын, матур бер традиция буенча, данлыклы «Зәңгәр шәл» белән ачып җибәрде. Быел тагын да иртәләделәр: Булатны 18 августта ук «кайтардылар». Алай гына да түгел, театр, гомер булмаганны, августта премьера тәкъдим итәчәк. Яңа сезонның тәүге премьерасын яшь, әмма тәҗрибәле режиссер Айдар Җаббаров куя. Илгиз Зәйниев пьесасы буенча куелган «Ситса туй» (16+) музыкаль комедиясен 25–27 август көннәрендә карый алачакбыз.

Чираттагы премьера 7 ноябрь – Марсель Сәлимҗановның туган көнендә көтелә. Режиссер Рамил Гәрәев Ркаил Зәйдулланың «Хан һәм шагыйрь» әсәренә нигезләнгән «Игезәк» (16+) тарихи спектаклен тәкъдим итәчәк.

Моннан тыш, яңа сезонда Фәрит Бикчәнтәев, чираттагы теләген тормышка ашырып, Туфан Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» (16+) спектаклен чыгарачак.

Тинчурин театры

Тинчуринлылар 90 нчы сезоннарын, һәрвакыттагыча, 15 сентябрь – Кәрим Тинчуринның туган көнендә ачарга ниятли. Рәсми төстә сезон ачылган көнне татар дөньясында бәхәс тудырырга өлгергән «Идегәй» дастанын (12+) (реж. – Туфан Имаметдинов) күрсәтәчәкләр.

Яңа сезонның премьералары турында иркенләп бер сөйләр әле театр. Әмма без кайбер серләрне белдек. Хәзер менә сезгә дә сөйлибез. Төгәл генә даталары билгеле булмаса да, яңа елга кадәр баш режиссер Туфан Имаметдинов ике премьера белән «сыйларга» вәгъдә итә:
•берсе – Шамил Фәрхетдиновның «Ай былбылым» әсәре,
•икенчесе – Мансур Гыйләҗевның «Көлмәгез, мин үләм» әсәре буенча.

Узган сезонда «Идегәй» дастаны, «Җилкәнсезләр» пьесасы кебек шактый җитди әсәрләр белән эш иткән режиссер бу юлы бөтенләй башка якка борылган.

Кариев театры

Театрда яңа сезонның премьералары турында сөйләргә ашыкмадылар. Тиздән белерсез, диделәр. Әмма без 2, 3 сентябрьдә булачак бер премьераның ачык репетициясендә булып кайткан идек инде. Кариев театрының баш режиссеры Ренат Әюпов яшьләр белән чираттагы спектакль – Александр Гринның данлыклы «Ал җилкәннәр» (12+) әсәрен феерия итеп күрсәтәчәк. Инсценировкасын Нәзифә Кәримова язган. Шактый үзенчәлекле спектакль ул. Берни дә үзгәртмәсәләр, тамашачы аны сәхнә түренә утырып караячак.

«Әкият» курчак театры

«Әкият»ләләр быел 90 нчы юбилей сезонын ача икән! Сезонның беренче спектаклен – «Конек-Горбунок» әсәрен 25 августта күрсәтәчәкләр. Яңа сезонны ачу өчен нәкъ менә рус телендәге спектакль сайлануы кызганыч булып тоелды. Премьераларга килгәндә, Галиәсгар Камалның «Беренче театр» һәм «Банкрот» пьесаларын берләштергән «Камал комедияләре» спектаклен (реж. – Илгиз Зәйниев) күрсәтәчәкләр.

Чаллы театры

Автокаладагы драма театры яңа сезонын «Диләфрүзгә дүрт кияү» (12+) спектакленең премьерасы белән 8 сентябрьдә ачарга ниятли. Моннан тыш та премьералар күп булачак:
•13 октябрьдә – «Ак калфак» (12+),
•1 декабрьдә – Нәбирә Гыйматдинованың «Сихерче» (12+),
•яңа елга аяк басканчы, «Хәл бу ки…» (12+),
•Илгиз Зәйниевнең «Пробка» (12+) пьесасы.

Әлмәт театры

79 нчы сезонын каршыларга җыенучы театр тамашачысына шактый премьералар әзерли. Яңа сезон 5 октябрьдә яңартылган залда Туфан Миңнуллин әсәренә нигезләнгән «Ат карагы» спектакленең премьерасы белән ачылачак. Аны Айдар Җаббаров чыгара. Моннан тыш, 30 ноябрь, 1 декабрьдә яшь режиссер Мурат Әбулкатинов Муса Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосына нигезләнгән спектаклен тәкъдим итәчәк.

Тагын бер яңалык: бу сезонда Әлмәт театры артисты Динар Хөснетдинов шул ук театр артисткасы Резеда Сафина-Хәйретдинова язган «Киңәш кирәк» пьесасын куярга әзерләнә. Премьера 14 декабрьгә тәгаенләнгән.

Февраль азагында Равил Сабырның «Фәхрине үтереп ташладылар» романына нигезләнгән спектакльнең премьерасын күрсәтергә ниятлиләр. Моннан тыш, фронтовик-язучы Рафаэль Төхвәтуллинны искә алу максатыннан, режиссер Ильяс Гәрәев тагын бер премьера әзерли. Моның белән дә бетми әле. Сезон ахырына таба Ркаил Зәйдулланың «Хан һәм шагыйрь» әсәре буенча казах режиссеры Алибәк Омирбекулы да спектакль куячак.

Буа театры

Буалылар быел яңа сезонны яңа бинада каршы алачак. Сезонны октябрь башында «Дәрвиш» моноспектакле белән ачачаклар. Моннан, яңа сезонда Кариев театры артисты Булат Гатауллин балалар өчен спектакль тәкъдим итәчәк. Шулай ук яшь режиссер Тимур Кулов та Ләбиб Лерон әсәре буенча спектакль әзерләп ята. Әле тагын Илдар Юзеев иҗатына багышланган «Кыр казлары артыннан» спектакленең премьерасын да әзерли буалылар.

Әтнә театры

Әтнәлеләр яңа сезонны 27 октябрьдә Мостай Кәрим әсәре буенча «Ай тотылган төндә» спектакле белән ачарга җыеналар. Аны режиссер Сойжин Жамбалова тәкъдим итәчәк. Тагын бер зур яңалыклары бар: яңа сезонда Әтнә театры каршында балалар театр студиясе эшли башлаячак.

Минзәлә театры

Минзәләдә театраль сезон 6 октябрьдә Юныс Әминовның «Гөлҗәннәтнең җәннәте» спектакленең премьерасы белән ачылачак. Режиссеры – Байрас Ибраһимов. Гомумән алганда, минзәләлеләр 88 нче театраль сезонда 8 премьера күрсәтергә ниятли. Быел Минзәлә театрына нигез салган Сабир Өметбаевның тууына 115 ел тулу уңаеннан да шактый чаралар узачак.

Түбән Кама театры

Туфан Миңнуллин исемен йөртүче театр яңа сезонны бик тиздән – 25 августта ачарга ниятли. 35 нче сезон ачылышы, әдипнең туган ягы Кама Тамагы районының Олы Мәрәтхуҗа авылында узачак. Бу көнне анда «Мәрәтхуҗадан – Туфан» театраль кичәсен тамаша кылып булачак. Шулай ук театр яңа сезонда:
•Ркаил Зәйдулла комедиясе буенча «Пачпортлы Шүрәле»,
•Туфан Миңнуллин комедиясе буенча «Әбрәкәй»,
•Антон Чеховның «Дядя Ваня» әсәренә нигезләнгән спектакль дә тәкъдим итәчәк.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

2023 елның 14 августы № 23/159 Казан ш.

2023 елның июлендә төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булган сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга сарыф ителгән эфир вакытын исәпкә алу нәтиҗәләрен раслау турында

Бирелгән мәгълүматны тыңлаганнан һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булган сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә сарыф ителгән эфир вакытын исәпкә алу нәтиҗәләрен билгеләү буенча эшче төркемнең 2023 елның 10 августындагы «2023 елның июлендә төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булган сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга сарыф ителгән эфир вакытын исәпкә алу нәтиҗәләре турында» 115 номерлы карары буенча фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булган сәяси партияләрнең эшчәнлеге төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртылганда, аларның тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2010 елның 11 ноябрендәге 35/392 номерлы карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булган һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә сарыф ителгән эфир вакытын исәпкә алу тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. Төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булган һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга 2023 елның июлендә сарыф ителгән эфир вакытын исәпкә алуның югарыда күрсәтелгән Эшче төркемнең 2023 елның 10 августындагы 115 номерлы карарында булган нәтиҗәләрен расларга.

2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм таратыла торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалы һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» – «Болгар радиосы» радиопрограммасы» төбәк радиоканалы тарафыннан 2023 елның июлендә Татарстан Республикасы Законының Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булган сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында таләпләре үтәлү хакында нәтиҗә чыгарырга.

3. Бу карарны «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «БЕРДӘМ РОССИЯ» бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлегенә, «РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ КОММУНИСТЛАР ПАРТИЯСЕ» сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлегенә җибәрергә.

4. Бу карарны, бастырып чыгару өчен, «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе урынбасары А.А. Нефедовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

«ГАБДЕЛФӘТ БАКЧАСЫНДА УЛ БУЛЫП ҖЫРЛАП ЙӨРДЕМ»

Бер пародия тарихы

Соңгы вакытта социаль челтәрләрдә бик матур бер видео таралды. Алып баручы, җырчы, Балтач егете Ирек ФАТЫЙХОВ танылган җырчы, үзенчәлекле тавыш иясе Габделфәт Сафинның «Чияләр» җырына пародия ясый. Ул җырлап бетерүгә, Габделфәт үзе килеп чыга. Һәм Ирекә: «Шәп булды бу!» – дип бәя бирә.

Иректән әлеге пародия тарихы турында сорашам. «Шушы пародияң белән социаль челтәрләрдә танылдың», – дим. Килешеп бетми. «Аннан алдарак Мөнир Рахмаевка, Фирдүс Тямаевка ясалганнарын күбрәк кеше караган иде», – ди. «Алары бит аның шаян рухта, туй мәҗлесләрендә яздырылган, монысы – Габделфәт каршында», – дим.

– Габделфәт абыйга моңа кадәр дә пародияләрне күп ясаган идем инде. Иң яратып җырлый, тыңлый торган җырчым ул. Ә «Чияләр»гә беренче тапкыр үз каршында пародия ясадым. Әле җитмәсә, үзендә кунакта чакта. Габделфәт абый бакчасында Габделфәт Сафин булып җырлап йөрдем.

:: Ничек шулай килеп чыкты? Үзең бардыңмы? Габделфәт чакырдымы?

– Шушы көннәрдә генә безне – пародистларны – «Башваткыч» тапшыруына чакырдылар. Аны 20 август көнне ТНВ каналыннан күрсәттеләр. Ә «ТНВ-Планета» алданрак күрсәткән иде. Габделфәт абый минем шунда Бәширә Насыйровага ясаган пародиямне караган. Үзенең «Яран гөл»енә ясаган пародиямнең язмасын җибәргән булганнар. Беркөнне телефоным шалтырый. «Ирек, Габделфәт абыең Сафин иде әле бу. «Башваткыч»та ай-яй туры китердең Бәширәне», – ди. «Минем тавышны да шулкадәр шәп итеп туры китергәнсең. Ничек шулай килеп чыга ул синең?» – ди. «Кыланып йөргәч, була инде ул», – дим. «Кыланып йөреп кенә алай килеп чыкмый шул ул», – ди. Җитди итеп әйткәндә, җырлый белүем пародия ясауга нык ярдәм итә.

:: Син «ВК»дагы битеңдә үзең белән «алып баручы, җырчы, пародияче» дип таныштырасың. Юкса син бит күптөрле мәртәбәле конкурсларда җиңү яулаган, бик өметле җырчы идең... «Сандугач керде күңелгә», «Татар моңы», «Йолдызлык» фестивальләре лауреаты, «Ягымлы яз» студентлар бәйгесе җиңүчесе, «Урмай моңы» халыкара җыр фестивале гран-при иясе, Кабардино-Балкариядә үткән «Алтын мәйдан – Эльбрус» төрки халыклар фестивалендә шулай ук гран-при иясе... «Иске кара урман»ны акапелла җырлап, гран-при алган Ирек ни өчен җырчы булып китмәде?

– Ул чакта җырчылар күп, алып баручылар аз иде. Мәктәптә укыган чакта ук туйлар алып баручы бер төркемдә җырлап йөрдем. Берничә елдан соң, ничектер, бер үк көнгә ике туйга заявка алганбыз булып чыкты. Үз ялгышымны үземә төзәтергә, ул туйны үземә алып барырга туры килде. Дөрес, бик нык әзерләндем. Башка төрле булсын дип, җырчыларга, төрле тапшыруларга пародияләр дә эшләдем. Якын дустым, авылдашым Илнур да ул чакта бик булышкан иде. Туй бик матур килеп чыкты. Тора-бара үзебез төркем оештырып, туйлар-никахлар алып бара башладык. Шулай итеп, зур сәхнә үзеннән-үзе икенче планга күчте.

:: Соңгы елларда районда үткән барлык рәсми чараларны да алып барасың. Дикцияң, сәнгатьле сөйләмең нәселдән киләме, үз өстеңдә эшләү нәтиҗәсеме?

– Икесе дә бардыр. Әти-әнием икесе дә сүзгә осталар, сүз тәмен белә торган кешеләр. Бала чакта мин бик оялчан булганмын. Әнием Розалия, кулымнан җитәкләп диярлек, бөтен конкурсларга йөртте. Сәләтемне ачуда, үстерүдә әниемнең өлеше бик зур. Атна саен үткән туйлар, никах мәҗлесләре, даими кешеләр арасында булу да, билгеле, үз эшен эшләде.

:: Ә Габделфәт бакчасына ничек килеп эләктең?

– Телефоннан шалтыраткач, ул мине үзенең булачак концертларында катнашырга чакырды. Соңгы вакытта күңел болай да сәхнә ягына тарта башлаган иде инде. Мәҗлесләрдә әйбәт кабул итүләре – бер нәрсә, ә сәхнәдән тамашачы ничек кабул итәр икән, дип уйлана идем. Риза булдым. Һәм тормыш иптәшем белән аларга кунакка бардык. Без бакчада сөйләшеп-җырлашып йөргәндә, җәмәгате Рузилә апа кухняда иде. Ачык тәрәзәдән минем җырлаганны ишеткән булып чыкты. Керүгә: «Габделфәт, бакчада син җырладыңмы?» – диде.

:: Ирек, мин сине бала чагыңнан ук беләм. 2005 елда «Ватаным Татарстан»да синең турыда «Унөч яшьлек имам» дигән язмам басылган иде. Син иң элек шушы яктан танылган идең, димәкче булам...

– Бу темага тирән керәсем килми. Динне сәхнәгә алыштырдың, диючеләр дә, гаепләүчеләр, тәнкыйтьләүчеләр дә булды. Шуны гына әйтә алам: сабый чакта күңелгә сеңгән әйберләр онытыла, югала алмый, алар минем дә күңелдә. Җомгаларга йөрим, уразаны, намазларны калдырмаска тырышам. Кайда гына булсам да, юк-бар җырлар җырламыйм, мәгънәле, тәрбияви сүзләргә өстенлек бирәм.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Премьера

«Бәлки тавык та оча башлар»

Сөенечле хәбәр! Кинорежиссер Байбулат Батулланың «Ядәч! Истә!» («Бери да помни») фильмы «Короче» кинофестивале конкурсында төп бүләкне алды. Кыска метражлы һәм дебют фильмнары кинофестиваленең ябылу тантанасы Калининградның Үзәк паркында үтте.

«Ядәч! Истә!» – Байбулат Батулланың тулы метражлы фильм төшерүдә беренче тәҗрибәсе. Фильм алты яшьлек Илһам турында. Ул җәйге каникулын әби-бабасы янында авылда үткәрә һәм әти-әнисен бик сагына. Оныгының ничек тә күңелен күрү өчен, бабасы (Рабит Батулла) «Ядәч! Истә!» уенын искә төшерә. Берзаман шул уенны уйнап, аларның теләкләре чынга аша башлый. Тора-бара әлеге уен бер гаиләнең генә түгел, бөтен авылның тормышын үзгәртә.

Җиңүчене игълан итеп, жюри рәисе, танылган режиссер Борис Хлебников:

– Мин бернәрсәгә дә ышанмыйм: яхшылыкка да, әхлакка да. Мин юмор хисенә генә ышанам – бу кешедә иң мөһиме. Ә режиссерның беркемгә дә охшамаган, үзенә генә хас юмор хисе бар икән, бу – бик зур бәхет, – диде.

«Хәзер миндә тавык та, күркә дә бар». Байбулат Батулла җиңүе турында әнә шулай диде:

– Барыгызга да зур рәхмәт әйтәсем килә. «Ядәч! Истә!» уенында сындыра торган сөяк тавык һәм күркәдә генә бар. Алар икесе дә – очмый торган кошлар. Ә «Короче» фестивале ярдәмендә бу кошлар, бәлки очып китәрләр!

«Бер күрүдә яраттык». Монысы – продюсер, Arna Media компаниясе президенты Надежда Мотинаның ТАССка биргән интервьюсыннан китерелгән сүзләр.

– Кино базарында мондый фильмнар прокат өчен авыр дип санала. Татар телендә татар фильмы, билгесез актерлар һәм катлаулы тема. Ләкин без бу фильмны бер күрүдә яраттык, чөнки ул милли мәдәнияткә һәм якыннарга чиксез мәхәббәт белән сугарылган. Аның хәтта иң «коры» кешеләрдә дә хисләр уятканын күрдек, – дип сөйләгән ул.

Фильмда Рәсим бабай ролен (төп герой) башкаручы, Байбулатның әтисе, күренекле язучы Рабит Батулла белән дә элемтәгә кердек.

– Үзем төшкән киногa мин бәя бирә алмыйм, нейтраль калам. Мактамыйм да, хурламыйм да. Байбулат – яшь режиссер, ул нәрсә әйтте, шуны эшләргә тырыштым. Фильмда актерлар – татарлар, режиссеры, ике сценаристы – татар. Шулай булгач, без аны татар киносы дип әйтә алабыз. Әнә шул ягы белән отышлы һәм әһәмиятле ул. 14 сентябрьдә кино киң прокатка чыгачак. Халык нәрсә әйтер. Сез дә килеп күрегез, – диде Рабит Батулла.

Ләйсән САФИНА



УКУЧЫ СҮЗЕ

Клубка кино килде

Азрак үсә төшкәч, әтием Әнәс мине үзе белән күрше авылларга кино куярга алып йөри башлады. Чапшар, Курмала, Көек, Кили, Пүскән, Нормабаш авыллары һәрберсе үзенчә истә калган. Гомумән, тирә-як белән танышуым, үзем дә сизмәстән, кинога бәйле булган икән минем. Әле хәзер дә әллә ниләр искә төшә.

Курмала авылына барганда, тирән, текә ярлы елга аркылы чыгарга кирәк. Бигрәк тә төнлә куркыта иде. Көек авылына барганда, үр менәсе. Миңа бу авыл нигәдер дөньяның чите кебек тоела иде. Аның каравы кешеләре бик кунакчыл булды. Берсеннән-берсе чибәр, шаян Билал бабай малайлары, гөрләшеп, клубка килеп керерләр иде. Карам, Рәис, Әкрәм абыйлар сүзгә шундый осталар, алар белән сүз көрәштермәвең хәерле. Ул да түгел, ишектән озын гәүдәле бер кеше күренә. Бу – Тимергали абый. Үзе рәссам, балта остасы, гармунчы, көрәшче, кыскасы, әллә нинди һөнәрләре бар. Ул гадәттә эти белән икебезне чәй эчәргә чакыра. Әнисе Мөнәвәрә апа бик кунакчыл кеше иде шул. Данлыклы көрәшчеләр Васыйл абый белән Мәлик абый Минһаҗевлар күренмәсә дә, күңелсез булып китә иде. Мәлик абый безгә бик ярдәм итте: нинди авыр кино моторын да арбага берүзе күтәреп сала иде. Васыйл абый районның абсолют Сабантуй батыры булды. Кили авылына барганда, зират яныннан үтеп китәргә кирәк, эти янәшәмдә булса да, бик шүрләтә иде. Бервакыт күрәбез: Чапшардан яшьләр кайтып килә. Әтием шаяртырга оста: мине зират кырыенарак алып барды да, яшьләр килеп җитәрәк, кычкырып җибәрде. Тик алар әтине тиз танып алдылар. «Әнәс абый, җитте инде!» – дип тавыш бирделәр. Нормабаш – әнием Рәфисәнең туган авылы. Бу авылны төрле яклап кап-кара урман чорнап алган. Серле, әкияти авыл, кешеләре бертөрле көйләп, матур итеп сөйләшәләр. Кечкенә вакытымда, әни белән җитәкләшеп, без анда кунакка йөрдек. Пүскән авылына барганда, биек тауга менәргә кирәк. Пүскән – тау башында үскән, диләр иде аның турында. Аннан кире кайтканда, сәпитеңнең тормозы тотмаса, беттең дигән сүз. Чапшар – туып-үскән бишегем, анда кино булган көнне шундый рәхәт, ерак барасы юк бит. Дусларым Мөхәммәтҗанов Фәргәп белән Хисамов Дамир да янәшәдә генә. Кинобудкадан, тылсымчы кебек, аппаратны кабызып җибәрәсең, дөньялар яктырып, нурланып китә. Һинд киносы булса, авылның аргы ягыннан Сәлахова Гайшә апа да чыга. Башка вакытта клубка йөрми иде ул. Клубтагы халык рәхәтләнеп кино карый, серле дөньяда яшәп ала. Урамдагы пычрак, салкын, яңгыр, бетмәс-төкәнмәс эшләр, бурычлар да онытыла. Кешеләр елмая, көлә башлыйлар, кемдер әкрен генә елап та ала.

Әтием куйган кинолар бу бәләкәй авыллар өчен менә дигән мәдәният учагы булган икән бит. Мин моны яши-яши аңлыйм. Бу авылларда әтине хәзер дә хәтерләүчеләр бар әле.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.
Казан

ЧИБӘРКӘЙЛӘР

Инде күптән ак сакаллы карт булсам да, хатын-кызларыбызга карап сокланып туя алмыйм. Озын аяклы, зифа буйлы чибәркәйләрнең урам буйлап салмак кына атлап баруларын күзәтеп тору – үзе бер дөнья рәхәте!..

Әйе, вакыт дигәнебез кешенең кыяфәтенә кадәр үзгәртә икән!

Гүзәлкәйләргә шулай карап сокланган чакларда, ирексездән, Сталин заманында колхозда яшәгән туташ-ханымнар күз алдына килеп баса. Бүгенге сылулар шул заманда яшәсә, сазаган кыз булып утырып калырлар иде, дигән гөнаһ уйлар да башыма килгәли. Ник дигәндә, ул чагында матурлык башкачарак бәяләнде.

Ат урынына сабан, арба тартып йөргән кызлар кыска юан аяклы, нык гәүдәле иде. Авыр хезмәт аларны шулай тупасландырды. Без, ир затлары, шундыйларны күбрәк яраттык та, чөнки нәфис гәүдәлеләр мондый эшкә түзә алмый. Шуңа күрә авылыбыздагы барлык егетләр шакмак гәүдәле тракторчы кызга гашыйк иде. Кыска юан аякларын як-якка куеп, көпчәкле тракторны, эһ тә итми, алгы күчәреннән күтәрә иде ул. Ирләргә тартым йөзе, карлыкканрак тавышы шыксызрак тоелса да, сазга баткан ат арбасын берүзе тартып чыгарганын күргән егетләр нәкъ менә шундый хатынга ия булырга хыялланды. Кызганычка, беребезгә дә эләкмәде ул. Эшкә батыр кызыбызны күрше авылдан арык кына гәүдәле бер укытучы алып китте.

Кыскасы, бүгенге тормыштан ничек кенә зарлансак та, начар яшәмибез дип уйлыйм. Барлы-юклы илле ел эчендә хәтта авыл хатын-кызларының да нәзакәтле, зәвыклы, зифа буй-сынлы чибәркәйләргә әйләнүе шундый фикергә этәрә мине.

Локман ЗАКИРОВ.
Казан

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ялгыз парлар

Мәхәббәтен сакламыйча, бездәй
Азмы инде җирдә ялгышканнар?!
Исемебез кеше телләрендә:
«Ялгыз парлар алар, ялгыз парлар…»

Суы корып, кибеп беткәндә дә
Мәңге кушылмыйлар каршы ярлар.
Мин бер аваз ишетәм ярлардан:
«Ялгыз парлар алар, ялгыз парлар…»

Син дә шулай сокланасың микән:
Нинди матур шушы язгы таңнар!
Карлы яңгыр чиртә тәрәзәмә:
«Ялгыз парлар алар, ялгыз парлар…»

Соңгы өмет булып язып куйган
Исемең дә эри язгы карда.
Гөрләвекләр елый-елый ага:
«Ялгыз парлар алар, ялгыз парлар…»

Безнең хәлне, безнең язмышларны
Үзебездәй тик бер ялгыз аңлар.
Бармак төртеп кала көзге җилләр:
«Ялгыз парлар алар, ялгыз парлар…»

Нурлан ГАНИЕВ

ТЕГӘРҖЕП УРАМЫНДА

Авылым урамы, кичке капка төбе… Нинди матур хатирәләрне яңарта бу сүзләр. Без дә бер кичне Көрнәле дигән авылыбызның иң озын Тегәрҗеп (борынгыдан килгән атамасы) урамында яшәүче Фәтхуллин Сөләйман белән Нурия капка төбендә җыелдык. Күрше-күлән, агай-эне, бала-чага – күп иде кеше. Шушы авылда туып, 30 яшькәчә яшәгән апам Рәвилә Ахунова, шулай ук Көрнәледә яшәп киткән җизнәм Зиннур Ахунов, Коръән укып, авылыбызга, шушы урамда, шушы нигездә яшәүчеләргә бәрәкәтле, хәерле гомерләр теләделәр, ил өстендәге борчулы хәлләрнең тизрәк таралып, бәла-казаларның авылыбызны читләтеп үтсен, борчулы гаиләләргә тынычлык килсен дип, Аллаһтан зур сабырлык сорадылар. Тегәрҗеп урамында азан яңгырады.

Капка төбендәге кич утыру мөнәҗәт әйтү, матур җырлар, биюләр, шушы урамда яшәүчеләрнең, кунакларның теләкләре, чыгышлары белән үрелеп барды. Зур казанда пешкән кайнар пылау ашап, күчтәнәчләр белән чәй эчеп сөйләшеп утыру онытылмас истәлек булып калды. Ә авылга кунакка кайткан балалар бәйрәмнән таралышканда, тагын кайчан җыелабыз, дип аптыраттылар.

Шушындый матур бәйрәмне оештырган өчен, авыл җирлеге рәисе Дилбәргә, кунаклар кабул итәргә риза гына түгел, шат булып, өстәлләр әзерләп, пылау пешергән Сөләйман – Нурия гаиләсенә, мәҗлесне күркәм итеп алып барган районның «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Алсу Нәҗметдиновага, барлык оештыручыларга, катнашучыларга бик зур

рәхмәт. Бәйрәмнәр дәвамлы булсын иде. Илләребезгә тизрәк тынычлык иңсен иде.

Резида ФАТЫЙХОВА.
Алексеевск, Коры Көрнәле

НЕФТЬЧЕ ГАБДЕЛБАРЫЙ

Йорт хуҗасы Габделвәли, салкын тидереп, бик каты авырып китә дә бакыйлыкка күчә. 1934 ел була бу. Фахирә апа җиде сабыйны җил-яңгыр тидерми, күз карасыдай күреп, тәрбияләп үстерә. Борынгылар, кайгы-хәсрәт ялгыз йөрми, дип белеп әйткәннәрдер: өч һәм дүрт яшьлек сабыйлары бер-бер артлы якты дөнья белән саубуллаша.

1937 елда җиденче сыйныфны туган авылы мәктәбендә тәмамлагач, уллары Барый, гаиләне авыр тормыштан коткару максатыннан, берәр төрле эшкә керергә ниятли. Яшүсмернең колагына, Иске Шөгер авылы янында нефть чыгара башлыйлар икән, дигән хәбәр ишетелә. Ул нефть бораулау оешмасына эшкә керә. Ярдәм итәргә бернинди техника юк, бар хезмәт кул көче белән башкарыла. Колхоздагы ат белән борауны әйләндерәләр. Эш салкын кышта да, буранда да тукталмый. Махсус вагоннарда кунарга туры килә.

Ике елдан дизель агрегаты китерелгәч, эш тизрәк бара башлый. Агрегат борауга беркетелә. Грунт пробиркалары биредә чыннан да «кара алтын» барлыгын күрсәтә. Барый бу җайланма белән тирәнтен кызыксынып китә, ватылган очракларда ремонтларга да үзе теләп алына.

Сугыш башлангач, нефтьче Вәлиев Габделбарый да, кулына мылтык алып, ил азатлыгын якларга китә. Фашист гаскәрләре инде Идел буена килеп җитә. Сталинград өчен аяусыз бәрелешләр башлана. Элемтәче Барый үзен кыю, батыр сугышчы итеп таныта. Яу кырында өч тапкыр яралана. Берничә тапкыр госпитальдә ятарга туры килә. Терелеп аякка басу белән, үз хәрби частен эзләп табып, фашистларны тар-мар китерүне дәвам итә. Курскидагы бәрелешләр дә Сталинградныкыннан ким булмый. Соңрак аларның часте легендар Украина фронтына кушыла. Сугышчан юлы Польша, Венгрия, Австриядә дәвам итә. Кенигсбергны азат итә.

Җиңү көненнән соң командирлар аңа, Германиядә калып, хезмәтен дәвам итәргә тәкъдим ясыйлар. Шулай итеп, Барыйга Германия башкаласында дүрт ел хезмәт итәргә туры килә. 1949 елда килешү тәмамлангач, туган ягына кайта. Аннары инде, җиң сызганып, сугышка кадәр хезмәт иткән җиренә – «Лениногорскнефть»кә килә. Эшкә йөрергә җиңел булсын дип, беренче хезмәт хакына мотоцикл сатып ала. Ярты елдан соң гаилә кора. Алабуга педагогия училищесын тәмамлаган тормыш юлдашы Миңзифа мәктәптә балалар укыта башлый. Фронтовик Барый исә бораулау җиһазларын биш бармагыдай әйбәт белә. Үзен югары категорияле слесарь итеп таныта. Җайлырак булсын дип, алар гаилә белән Лениногорскига күченәләр. Башта Әгъзәм, бер елдан Әгъләм дөньяга аваз сала. Өлкән уллары беренче класска укырга кергән елны Әкрәмне көтеп алалар. Аңа бер яшь дигәндә, ике бүлмәле фатир бирәләр. Барый туган авылы Мөэмин-Каратайны бик сагына. Әнисенә түбәсе шифер белән ябылган зур йорт салып бирә. Ул өйнең урыны зират каршысында була. Мәчет эшләмәү сәбәпле, җомга намазларын Барый абый салган өйдә укыйлар. Гаилә җәйге каникулларда авылда яши. Балалар җәйләрен су кереп, балык тотып, җиләк җыеп көн итәләр. Печән җыялар, бакчада булышалар, бәрәңге алалар…

Фронтовик, «кара алтын» чыгаручы Габделбарый Вәлиевнең озак елларга сузылган фидакарь хезмәте югары бәяләнә: ул I һәм II дәрәҗә Хезмәт даны орденнары белән бүләкләнә. Дистәләрчә уйлап табучы дипломнары, таныклыклары ала. 1981 елда «Волга» машинасы бүләк итәләр. Аның яу кырындагы батырлыклары өчен бирелгән бүләкләре дә бихисап. Алар барысы да Лениногорск шәһәре музеенда саклана.

Габделбарый Вәлиев 1991 елның 18 маенда, үзенең туган көнендә, озак вакыт авырганнан соң вафат була. Ил каршындагы фидакарьлеге, батырлыкларын исәпкә алып, Бөек Җиңүнең 78 еллыгына уздырылган митингта Бөек Ватан сугышына багышланган һәйкәл янына каһарман авылдашыбызның бюсты да куелды.

Таһир ШӘМСУАРОВ.
Лениногорск

Авылча яшәп ятыш

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Бу рубрика сезнең күңелләргә бигрәк тә хуш килер, мөгаен. Сез ниләр майтарып ятасыз? Нинди яңалыклар бар? Языгыз әле безгә. Башкалар белән дә уртаклашыйк. Әлегә без сезне бүген Башкортстандагы туган авылында яшәп ятучы күренекле журналист **Флюра НИЗАМОВА**ның хәл-әхвәлләре белән таныштырабыз.

СӘЕР ЕЛ

Бик сәер ел әле бу. Башта корылык, эсселек интектерде. Июнь аенда барлык яшелчәләр, суыктан бөрешеп, кибегеп-көеп утырдылар. Ниһаять, берара яңгырлар явып алгач, хәлләнеп киттеләр тагы. Минем ындырда җәй башының суыгына һәм җирнең дымсызлыгына караптыр инде, алабута чыга алмады хәтта. Бары тик эт эчәге генә бирешмәде: аның, күрәсең, тамыры бик тирәнгә китә, ул үзенә җитәрлек дымны табып ала, ахрысы – котырып үсте. Бәрәңгене, кавын-карбыз-кыяр араларын инде ике кат утап чыккан идем, бүтән чүп әллә ни үсмәс дип уйлаган идем. Үсмәс ди сиңа: июльдә көннәр җылыга борылгач, өстәвенә ара-тирә яңгырлар да яугалап алгач, алабута ирәеп китте. Бер атна-ун көн утамый торган идем, берзаман бөтен ындырны алабута басты. Инде бу атнада бәрәңгене өченче катка утыйм. Чөгендер, суган, кишер, кыяр, кавын, карбыз араларын да яңадан утыйсы була инде, бәрәңгене дошманнан арындыргач. Урманга җиләккә йөрисе булмый быел, җиләк юк, диделәр. Корылык галәмәте инде. Алай ук булып чыкмады: урыны-урыны белән, урман авызларында, күләгәлерәк җирләрдә җир җиләге үскән дә пешкән икән. Биш тапкыр гына барып калдым. Бөтенләй үк җиләк өзмәдем диярлек булмады, шөкер. Җиләк уңган елларда унбиш тапкыр да барыла иде. Әле унике банка кайнатып ябып та куйдым. Инде бүтән җыясы нәрсә калмады, дип йөри идем, өч-дүрт көн элек күрше хатыннарыннан ишетеп, хәйран калдым: урманда бераз кура җиләге бар икән, кемдер барган, җыйган! Машиналы күршеләремә тагылып, кичә мин дә тауга менеп киттем. Без бала чакта тау өстендәге урманда делянка кисәләр иде дә, шул киселгән урында агачларны төпләп, яндырып, тазартып, трактор белән канаулар казыйлар, шунда нарат үсентеләре утырталар иде. Ике-өч ел эчендә ул наратлар шактый үсеп, тирә-ягында каен, усак та буй җибәреп, матур гына чаукалык барлыкка килә, ә араларында, котырып, кура җиләге үсә, ботаклары канау уртасындагы яшь наратларга таба иелеп, җиләкләре җыеп бетермәслек күп була торган иде. Хәзер исә урманны кисүен кисәләр, ләкин киселгәне урынына агач утыртуны оныттылар, ахрысы, урыны агач-богачтан чүпләнеп кала. Урманчылыкта да шул ук оптимизация хәлләре бугай: әллә күпме белгечлек бетерелгән. Хуҗасызлык, кыскасы. Менә шуңа күрә урманда элекке шикелле җиләкле кисентеләр бетте безнең тирәләрдә. Нефтьчеләр тау башына юл салганнар иде, үзләренә кирәк булгач. Ә юлны салганда тагы әллә күпме урманны кисеп, комын эттереп, юлның ике ягында да биек бер мәйдан барлыкка килгән, анда төрле агач-куак, шул исәптән кура җиләге дә үскән. Черегән агачларны таптап, күрән, кычыткан баскан урынны ергалап, кура җиләге эзләп йөрдек. Җиләге быел вак кына, июль ахыры бит: пешеп, изрәп, коелып бара. Алай да кечерәк чиләкләрне тутырдык. Берзаман аска карасам, үлән, чатыр-чотырлар арасында сары эшләпәле гөмбәләр күренә. Майлы гөмбә бит бу! Бәрәңге белән кыздырып ашарга менә дигән инде. Пычак һәрвакыт үзем белән, машинага чыгып, савытлар салган зур гына букчамны алып килдем дә, җиләкне онытып, гөмбә җыярга тотындым. Аннан тагы яхшы гына җиләклек очрады. Шулай, аралаштырып, икесен дә җыйдым. Эсседән әлсерәп, арып кйтып киттек. Чәй куеп җибәрдем дә гөмбәләрнең эшләпәләрен салдырырга тотындым. Аннан соң гына җиләккә чират җитте, тагы бер кат кулдан үткәреп, тазартып, шикәр бутап куйдым да клубка, репетициягә киттем. Җырлап кайткач, кура җиләген бер кат кайнатып алдым. Иртәгә, кем әйтмешли, урманга бардым юк, мондый эсседә җиләк дип үлеп булмый инде: теге кайнатманың эшен бетереп, банкаларны кайнарлап ябасы булыр. Ә гөмбәне пешереп алдым да бәрәңге (игътибар: яңа бәрәңге!) белән кушып, томалап пешердем. Телне йотарлык булды! Менә сезгә соңарган кура җиләге белән шулай ук гадәттә июль башларында ук чыга торган, ә быел соңарган гөмбә кыйссасы.

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстанда яшәүче төрле милләтләрнең традицион уен кораллары белән таныштыра. Аның чираттагы чыгарылышын ДӘФкә багышлыйбыз. Гомумислам мәдәниятендә зур урын алып торучы әлеге борынгы уен коралы гарәп-фарсыларда һәм төрки халыкларда таралган. Мәҗүсилек дәвереннән алып безнең көннәргә кадәр ул нинди юл үткән? Аның киләчәге бармы? Без әнә шул сорауларга җавап бирергә тырыштык.

Милли аккорд

МАХСУС ПРОЕКТ

ДӘФ ЯСАУ ОСТАСЫ ФАРАТ ХАНБӘКОВ:

«ТАТАРЛАРНЫҢ ГЫНА ТҮГЕЛ, БАШКА ХАЛЫКЛАРНЫҢ ДА ТАРИХЫ УЛ»

Бәрмә уен коралларын, аерым алганда, дәф ясау ни дәрәҗәдә катлаулы һәм ул нәрсәсе белән кызыклы? Дәфнең киләчәге бармы? Бу һәм башка сорауларга төрледән-төрле бәрмә уен кораллары ясау остасы Фарат ХАНБӘКОВ җавап бирде.

:: Фарат әфәнде, дәф ясау белән кайчаннан бирле шөгыльләнәсез?

– Дәфкә кадәр башка бәрмә уен кораллары ясадым. 2002 елда дөңгер (бубен) ясарга өйрәндем, 2006 елдан дәфләр ремонтладым. Ә инде 2009 елда дәф һәм барабан ясарга өйрәндем. Бер еллап шомаргач, рамлы дәфләр ясарга да алындым.

:: Кемнән өйрәндегез?

– Үзлектән. Төрек, азәрбайҗан, үзбәк һәм төрекмән дәфләрен карап, озаклап аларның яңгырашын тыңладым. Аннан соң татар көйләренә ята торган, безнең мотивларга туры килә торган инструмент ясарга керештем. Төрле диаметрда, калынлыкта ясап карадым. Кыскасы, шактый гына эзләндем.

:: Ни өчен нәкъ менә бәрмә уен кораллары җәлеп итте сезне?

– Алар белән кызыксыну балачагымнан ук килә. Бәрмә уен коралларының тавышы, яңгырашы шулкадәр… куәтле! Электән үк терапия кебек тәэсир итте ул миңа.

:: Дәф ясау технологиясе турында да сөйләгезче. Нинди материаллар кулланасыз?

– Дәф ясау өчен берничә төрле каты агач туры килә. Фанера, шпон, ламель кебек материаллар да ярый. Шуларның берәрсен сайлап, тиешле озынлыкта кисеп, баш-башын тоташтырам. Гади итеп әйткәндә,

түгәрәк килеп чыгарга тиеш. Шул түгәрәккә кәҗә тиресеннән чистартып ясаган мембрана ябыштырыла. Аны ясау өчен шактый гына вакыт кирәк. Бу – заманча технология. Борынгы технология белән эшләмим.

:: Сездән кала, Татарстанда дәф ясаучы осталар бармы?

– Очратканым да, ишеткәнем дә юк.

Фарат Ханбәков ясый торган дәфләрнең бәяләре:
- ✓гади дәф – **6 мең сум**;
- ✓эчке өлешенә велосипед камерасы куеп ясалган дәф – **11 мең сум**;
- ✓рамлы дәф – **12 мең сум**.

:: Ә сораучылар?

– Дәф сорап килүчеләр күп димәс идем. Моның сәбәбе берничә дип уйлыйм. Беренчедән, мине дәф ясаучы оста буларак белүчеләр аз. Икенчедән, дәфтә уйнарга өйрәтүчеләр юк дәрәҗәсендә. Мин ясаган дәфләр «Сорнай», «Риваять», «Алпар» ансамбльләрендә, Татарстанның дәүләт җыр һәм бию ансамблендә, төрле мәдәният йортларында, театрларда бар.

:: Димәк, дәф ясау – артык керемле кәсеп түгел?

– Кызганыч, юк. Татарстан дәрәҗәсендә популяр уен коралы түгел шул ул. Әйткәнемчә, уйнарга өйрәтүчеләр аз. Алар күбрәк булса, аңа карата кызыксыну да, ихтыяҗ да артыр иде.

:: Аның киләчәге хакында нәрсә әйтә аласыз?

– Аның киләчәге булырга тиеш. Һичшиксез! Сүз Татарстан турында гына бармый. Бу уен коралы бик күп төрле халыкларның үткәне, тарихына бәйле бит. Ул тарихны сакларга, киләчәк буынга тапшырырга кирәк. Моннан тыш, дәфне күп кенә заманча стильдәге көйләрдә дә кулланып була. Шул рәвешле ул заманча музыка сәнгатендә үз урынын табар иде.

:: Аны саклап калуның нинди юллары бар?

– Барысы да гап-гади. Дәфкә карата кызыксыну уятыр өчен, аны сәхнәләрдән күрсәтергә кирәк. Концертлармы ул, спектакльләрме – мөһим түгел. Иң мөһиме, дәфтә уйнау ысулларын, аның яңгырашын башкаларга җиткерергә кирәк.

БЕЗНЕҢ КУЛДА

Дәфнең яңгырашы кемне генә битараф калдырыр икән? Казан дәүләт консерваториясенең III курс студенты Рамилә Шәмсемөхәммәтова, шул яңгырашка гашыйк булып, аны тормышының бер өлешенә әйләндергән. Консерваториядә эшләүче «Бәрәкәт» фольклор ансамбленең солисты да ул.

Рамилә безгә дәфтә уйнау серләрен дә сөйләде, үзләре башкара торган борынгы көйләр белән дә таныштырды.

– Консерваториягә укырга кергәнче, минем әлеге уен коралы турында ишеткәнем дә юк иде. Геннадий Михайлович (Макаров. – **Авт.**) үз дәресенә дәф алып килеп, уйнап күрсәткәч, зур кызыксыну уянды. Аның үзенчәлекле яңгырашы үзенә гашыйк итте, дисәм, арттыру булмас, – дип искә ала Рамилә.

«Бәрәкәт» ансамбленә консерваториянең этномузыкология бүлегендә укучы студентлар гына йөри икән. Тарихка мәхәббәт каннарына сеңгән егет-кызлар ягъни.

– Без ансамбльдә җиде кеше. Алты кыз янында бер егетебез бар. Дәфтән тыш, думбра, саз кебек уен коралларында уйныйбыз һәм аларга кушылып җырлыйбыз. Татар, удмурт, мари көйләрен башкарабыз, – дип сөйләде ул.

Һәр музыка уен коралының үзенчәлеге була. Дәф, читтән карап торганда, бик гади төзелешле булып тоелса да, тиешле тавыш чыгару өчен, шактый азапланырга туры килә икән.

– Бер авырлыгы да юктыр инде, дип уйлыйсың башта. Әмма сиңа кирәк булган тавышны чыгарыр өчен, бик күп уйнарга, эзләнергә, үз өстеңдә эшләргә кирәк. Гомумән, этномузыка өлкәсенең төп таләпләре шундый. Шунысы белән кызыклы да ул. Хәзер инде шушы мохиттә кайнагач, дәфтә уйнау бик авыр кебек тоелмый, – дип сөйли булачак белгеч.

Тырышлыгы һәм ритм тоемлау сәләте җитсә, дәфтә теләсә кем уйный ала. Әмма икесе дә – бик мөһим шарт. Моннан тыш, дәфнең теләсә нинди көйләрне башкару өчен бара торган уен коралы булмавын да онытмаска кирәк. Бу җәһәттән «Бәрәкәт»нең репертуары белән кызыксындык.

– Көйләр төрле чорларга карый. Төрле еллардагы экспедицияләрдә яздырылган борынгы көйләрне дә, Геннадий Михайлович үзе язган көйләрне дә башкарабыз. Әйтик, 1978 елдагы экспедициядә яздырган «Хан кызы», керәшен шагыйре Яков Емельянов шигыренә Геннадий Михайлович язган «Олыларны санау» дигән көйләрне көйлибез. Мин үзем башкара торганнардан «Туйбикә мәдрәсәсе» тарихи бәете («Идегәй» дастаныннан өзек. – **Авт.**), мөнәҗәтләрне атый алам, – ди Рамилә. – Без башкара торган җырлар, көйләр күп очракта кешеләргә таныш түгел. Әмма алар зур кызыксыну уята.

Кызыксыну, димәктән, «Бәрәкәт» белән кайларда гына чыгыш ясамаган алар.

– Быел бигрәк тә күп чыгыш ясыйбыз. Болгарга, Мәскәүгә бардык. Миңа калса, кешеләргә этномузыка юнәлеше, борынгы көйләр кызыклы. Бүген ул актуаль.

> Дәф – безнең милли тарихыбызның бер өлеше. «Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», – дигән Шиһабетдин Мәрҗани. Ә инде дәф кебек уен коралының кулланышта булуы көйләребезгә матурлык, милли аһәң өсти.

Рамилә кебекләр булганда, тарих яшәр, дигән өмет тә яши. «Дәфнең киләчәге – без – тарихи музыка белгечләре кулында», – ди бит ул үзе дә. Үзләре өстендәге җаваплылыкны бик яхшы чамалый.

Бу кызык!

- Дәф азәрбайҗаннарда – гавал (әзери. Qaval), үзбәкләр һәм таҗикларда дойра (таҗ. дойра) дип атала.
- Азәрбайҗаннарның мугам, тәсниф кебек традицион жанрларында дәф кулланыла. Тар, кәманча һәм дәф уен кораллары азәрбайҗаннар музыка сәнгатендә «мугам» триосын тәшкил итә.
- Дәфче, уен коралын ике кул белән тотып, бармак белән уйный, кайбер вакытта бер кулы белән тотып, икенче кулы белән суга.
- Әүвәлге заманнарда бәет, мөнәҗәт һәм борынгы җырларны дәфсез башкармаганнар.

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Геннадий МАКАРОВ, сәнгать белеме кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе доценты

Урта гасыр татар сәнгатендә язма шигырьләр үзенчәлекле вәзеннәргә корылган. Ул шигъри әсәрләрдән касыйдә, газәл, робагыйларны көйләп укыганда дәф исемле бәрмә уен коралын кулланганнар.

Дәф берьяклы мембранофон төренә карый. Диаметры 400 мм, биеклеге 70 мм булган агач кыршаудан эшләнә. Бер ягыннан махсус эшкәртелгән бозау тиресе тарттырылып, җилем белән ябыштырыла. Кыршауның эчке ягына тимер боҗралар тагыла. Кырый ягына яисә уртага якынрак чиртүгә карап, дәф тавышы төрле тембр төсмерләрендә яңгырарга мөмкин.

Урта Идел татарлары мәдәниятендә дәф XIX йөз уртасында кулланыштан төшә һәм 1990 нчы еллардан алып яңадан тергезелә башлый. Бу күркәм традицияне кайтару өчен көйләп уку мәкамнәренең чынбарлык ритм тибешен, агышын, үлчәмен белеп, кадими өслүбкә якынайтыр өчен, аларның дәф озатылышын күз алдына китерергә кирәк. Көйләп уку мәкамнәренең өслүб сыйфатларын аңлар өчен, XX йөз башы сәнгатен генә түгел, күпкә тирәнрәк яткан, Урта гасырларга хас иске татар классик музыка сәнгатенең башкару өслүбләрен исәпкә алу мөһим.

Кадими заман музыкаль-шигъри әсәрләрдәге классик вәзен (метр) һәм икагъ (ритм) үзенчәлекләрен ачык чагылдырып башкару өчен, төп уен коралы булып дәф исемле бәрмә уен коралы тора.

Башка төрки-татар кавемнәрдә кебек үк, татар халкының иң борынгы бәрмә уен коралын берьяклы рамлы мембранофон тәшкил итә. Аның төрле тарихи дәверләрдә үзенә хас конструкциясе, репертуары, функцияләре үзгә булган. Табигый ки, ул төрле дәверләрдә төрлечә аталган да.

1 **Мәҗүсилек** дәверендә, ягъни имче, күрәзәче, багучы, күремчеләр кулланышында ул дөңгер дип аталган.

2 **Классик ислами сәнгатькә** бәйле татар көйчеләре аны дәф дип атаганнар.

3 **Яңа вакытта**, ягъни җәдитчелек дәверендә шөлдерле барабан дип йөрткәннәр.

Татар халкының Урта гасырлар инструменталь сәнгатендә дәф уен коралында башкару традицияләре Идел буеның ислам цивилизациясе мохитенә керү белән башланып китә, әмма яңа вакыт дәверендәге милли сәнгатьтә дәфтә башкару традицияләре, алымнары югала һәм бу уен коралы онытылуга дучар ителә. Билгеле ки, бу уен коралының репертуарын, башкару алымнарын ретроспекцияле анализ аша тергезү проблемасы хәзерге көн тәртибенә куелу гаҗәп түгел.

Әйтергә кирәк, язма шигърият белән аерылгысыз булган иске татар вокаль сәнгатенә хас илаһи һәм дөньяви әсәрләрнең башкару өслүбен кайтару барыннан бигрәк дәфтә башкарылган алымнарны кайтаруга бәйле.



Дәфнең схематик рәсеме (авт. – Г.Макаров).

Татар мәдәниятендә дәф турында булган мәгълүмат чыганакларының беразын күзаллыйк. Татар җәмгыятенең хәяти мәнфәгатьләре чагылган, татар зыялылары тарафыннан язылган дини, тарихи, әдәби эчтәлекле хезмәтләрдә берьяклы түгәрәк рамлы мембранофонны билгеләр өчен совет хакимияте дәверенә кадәрле тик дәф атамасын гына кулланганнар. Мәсәлән, С.Кукляшев төзегән хрестоматия сүзлегендә ул дәф, дәф чалмак – «тимпан», «играть на тамбуре» формасында телгә алына. Мондый язмаларда әлеге уен коралын «Татарныкы дип санаргамы, санамаскамы?» дигән сорау куелмаган.

> Ул, бернинди бәхәссез, гомумислам цивилизациясенең мәдәни киңлегендә барча халыкларның классик уен коралы булып саналган.

Төп бәхәс башка бер сорау тирәсендә куерган: «Мөселманнарга дәфтә уйнарга ярыймы, ярамыймы?» Бу мәсьәлә XX йөз башында иҗат иткән күренекле татар зыялысы Һади Килдебәки хезмәтләрендә дә күтәрелә. Үзенең «Музыка вә ислам» дигән китабында ул «Музыка кораллары ислам күзлегеннән рөхсәт ителәме яки юкмы?» дигән сорауга һаман да җавап юклыгы турында әйтә.

Әмма шул ук вакытта күпчелек Шәрык халыклары максатчан һәм цивилизацияле рәвештә үзләренең мәдәни мирасларын саклау эшен дәвам иттерә. Аларда дәф кенә түгел, башка классик Шәрык уен коралларында башкару сәнгате дә яшәп килә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5129 данә
Гомуми тираж – 14057 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 318

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+